ЧӘРШӘМБЕ
10 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 83 (5883)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Язгы чәчүне большевистик оешканлык белән үткәрик

Республикабызның көньяк-көнчыгыш һәм Кама арты районнарының кайберләрендә өлгергән участкыларда кыр эшләре башланды. Кыр эшләре массовый күләмдә башлануга санаулы көннәр генә калып бара.

Чәчү башлануга кадәр калган һәрбер сәгат, һәрбер көн чәчүгә хәзерлекне тулысынча төгәлләүгә файдаланылырга тиеш. Райондагы партия, совет һәм комсомол оешмалары, җир органнары, МТС һәм совхоз директорлары, колхоз председательләре язгы чәчүгә хәзерлек буенча материаль һәм оештыру ягыннан булган барлык җитешсезлекләрне бетерү өчен кискен чаралар күрергә һәм чәчүне тулысынча хәзерлек белән, зур оешканлык белән каршы алуга ирешергә тиешләр.

Язгы чәчүгә керешү—ул, югары иген уңышы өчен көрәшнең хәл иткеч чорына керү дигән сүз. Республикабызның партия, совет оешмалары, җир органнары алдында торган иң зур бурычлар: язгы чәчүне максимум кыска срокларда, агротехник яктан югары дәрәҗәдә, яхшы сыйфатлы итеп үткәрүне оештырудан гыйбарәт.

Язгы чәчүне иң кыска срокта үткәрү өчен аңа оператив җитәкчелек итәргә, кыр эшләрен вактында башларга, бөтен кырның өлгерүен көтеп тормыйча, өлгергән һәрбер участкыда эшкә керешүне оештырырга кирәк.

Язгы чәчүнең уңышлы үткәрелүен кешеләр — кадрлар хәл итәләр. Моны нык истә тотарга кирәк. Язгы кыр эшләрендә катнашучылар турында кайгыртучанлык күрсәтү, аларга барлык уңайлылыклар тудыру һәрбер колхоз председателенең, партиянең, комсомолның башлангыч оешмаларының, совхоз һәм МТС директорының игътибар үзәгендә торырга тиеш. Һәрбер трактор бригадасы вагоннарын культуралы хәлгә китерү, аларны газета-журналлар белән, музыка кораллары белән тәэмин итү, җәмагат туклануын үрнәк рәвештә оештыру—бурыч әнә шул. Ерак участкыларда эшләүче колхозчылар өчен кыр станнарында куну эшен һәм анда җәмагат туклануын оештырырга кирәк.

Республикабызда йөзпотчылар хәрәкәте киң колач алды. Йөзләрчә ефремовчы звенолар төзелде. Социалистик игенчелегебездә стахановчыл хезмәтнең бу яңа төрләре, формалары урыннардагы партия, совет, комсомол оешмалары тарафыннан, колхоз, совхоз һәм МТС җитәкчеләре тарафыннан зур игътибар бирүне таләп итә. Массовый - политик агитациянең бөтен методлары һәм формалары бу яңа гүзәл хәрәкәтнең тагын да үсүенә һәм һәр яклап ныгуына юнәлдерелергә тиеш. Менә инде монда һәрбер җитәкче үзенең сәләтлелеген ачык итеп күрсәтергә тиеш.

Чәчүнең уңышлы үткәрелүен тәэмин итүдә, массовый-политик агитация эшләрен җәелдерүдә партия оешмалары, аерым алганда һәрбер коммунист һәм комсомолец авангард роль уйнарга тиешләр. Моның өчен колхозлардагы коммунистларның иң зур күпчелеге турыдан-туры колхоз производствосында булырга, бригадаларда, звеноларда массовый-политик эшләрне оештыруның башында булырга тиешләр. Алар үзләренең яхшы эш үрнәкләре нигезендә, колхозчылар, тракторчылар, совхоз эшчеләре арасында масса-аңлату эшләрен яхшы итеп оештыру нигезендә язгы чәчүнең уңышлы баруын һәм төгәлләнүен тәэмин итәргә тиешләр.

Партиянең, комсомолның һәрбер башлангыч оешмасының эшен тагын да активлаштыру, партия көчләрен язгы чәчү вактында дөрес урнаштыру, коммунистларның, комсомолецларның производстводагы авангардлык рольләрен тагын да күтәрү, политик-агитация эшләрен киң рәвештә җәелдерү—партиянең район комитетларының иң әһәмиятле бурычларыннан берсе булып тора.

Язгы чәчүне оешкан рәвештә, югары дәрәҗәдә үткәрү бурычына районнардагы барлык оешмаларның эшен, игътибарын буйсындырырга кирәк. Кыр станнарына агитаторларны да, күчмә көтепханәләрне дә, хат ташучыларны да, кооператорларны да, күчмә киноларны да, художество бригадаларын да җибәрергә кирәк. Кайбер райкомнар һәм башлангыч оешмалар бу эшне оештыру буенча бик яхшы чаралар күрделәр. Мәсәлән, ВКП(б) ның Теләче райкомының булышлыгы белән „Марс №2“ колхозы янындагы башлангыч партоешма язгы чәчү вактында политик-масса эшләрен үткәрү буенча конкрет план төзегән. Бу планда башлангыч партоешманың, һәрбер коммунистның, комсомолецның язгы чәчү вактында нинди эш алып барырга тиешлеге, алдынгыларның эш тәҗрибәләрен башкаларга нинди юллар белән күчерү мәсьәләләре ачык итеп чагылдырылганнар. Бу планны үтәү өчен авылның барлык культура көчләре тартылган. Мондый мисальләрне башка күп кенә районнардан да китерергә мөмкин.

Бурыч—һәрбер колхозда, совхозда, бригадада массовый-политик эшне планлы рәвештә алып баруны оештыру.

Язгы чәчүгә оператив җитәкчелек итү—ул, кыр эшләрендә стахановчыл хезмәтнең иң яхшы үрнәкләрен вактында күрә белү, аны башкаларга күчерә белү, артта калып баручыларга кичекмәстән ярдәм итүне оештыра белү дигән сүз. Партия, совет оешмалары һәм җир органнары моны хәтерләрендә нык тотарга һәм практик эштә большевистик җитәкчелекнең көчен бөтен тулылыгы белән күрсәтергә тиешләр.

Партия органнарына соңгы сайлаулар чорында колхозлардагы башлангыч партоешмалар җитәкчелегенә күп кенә яңа кадрлар күтәрелде. ВКП(б) райкомнары язгы чәчүне үткәрү эшендә, политик-масса эшләрен оештыруда бу кадрларга аеруча ярдәм итәргә тиешләр.

„Барлык мәгълүматларга караганда, 1940 нчы ел иген уңышы өчен уңайлы ел булачак. Көз көне һәм кыш буена булган бик күп явым-төшем яхшы иген уңышы булачакны күрсәтәләр. Ләкин бу билгеләр никадәр генә яхшы булсалар да, җиңү үзлегеннән килмәс, югары иген уңышын алдан хәзерләргә кирәк, аны колхозларның, МТС ларның һәм совхозларның яхшы эшләүләре белән тәэмин итәргә кирәк“ (А. Андреев).

Иптәш Андреевның бу күрсәтмәләрен һәр вакыт истә тотарга тиешбез.

Кызыл Армиянең начальниклар составын һәм кызыл армеецләрен бүләкләү

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен СССР Верховный Советы Президиумы Кызыл Армиянең начальниклар һәм кызыл армеецләр составыннан, начальниклар составы семьяләре членнарыннан, госпитальләрнең һәм гражданский учреждениеләрнең работникларыннан 11.744 кешене СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләде.

Ленин ордены белән 180 кеше, **Кызыл байрак** ордены белән 2.598 кеше, **Кызыл Йолдыз** ордены белән 3.032 кеше, **„Батырлык өчен“** медале белән 2.396 кеше һәм **„Сугышчан хезмәтләр өчен“** медале белән 3.538 кеше бүләкләнде.

Барлык бүләкләнүчеләрнең исемлеге „Красная Звезда“ газетасында иглан ителәчәк. (ТАСС).

ХРОНИКА

Шушы елның 12 нче мартында Совет Социалистик Республикалар Союзы белән Финляндия Республикасы арасында солых договоры төзелү һәм СССР белән Финляндия арасында сугыш хәрәкәтләренең тукталуы уңае белән шушы елның 13 нче мартыннан 12 сәгатьтән башлап Финляндиянең яр буйларында һәм аңа караган суларда Наркоминделның 1939 нчы ел 7 нче декабрь һәм 1940 нчы ел 3 нче февраль ноталары белән иглан ителгән блокаданың туктатылганлыгын Чит Ил Эшләре Халык Комиссариаты Москвадагы илчелекләргә һәм миссияләргә белдерде.

ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕКНЕ ТИКШЕРҮ БУЕНЧА ЭШЧЕ-АВЫЛ ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ РЕЙДЕ

Рейд зур ярдәм итте

(Махсус хәбәрчебездән)

ШӨГЕР, 8 апрель. **(Телефон буенча).** Шөгер районында чәчүгә хәзерлекне тикшерү рейде „Дружба“ колхозының чәчүгә бөтенләй хәзер түгеллеген ачты. Бер генә центнер орлык та тиешле кондициягә китерелмәгән. 44 центнер карабодай орлыгы чиктән тыш дымлы булу сәбәпле бозылу куркынычы алдында тора. Орлыкларны яровойлаштыру өчен 1.000 квадрат метрлы урын кирәк. Ләкин бу турыда уйлап караучы да булмаган.

Рейд бригадасы тикшерү йомгакларын колхоз правлениесе утырышына куеп җитешсезлекләрне ашыгыч бетерү буенча эшлекле тәкъдимнәр бирде, сроклар билгеләнде. Артта калган һәрбер участкыга рейд бригадасы членнары, колхоз правлениесе членнары һәм активлар беркетелде. Хәзер кимчелекләрне бетерү өчен кызу эш алып барыла. Орлыкларны чистарту эше сменалап оештырылды. Яровойлаштыру өчен урыннар хәзерләнде. Атларны тәрбияләүдәге кимчелекләрне һәм хуҗасызлык күренешләрен бетерү өчен практик чаралар күрелде.

Язгы чәчүне кыска срокта югары сыйфатлы итеп үткәрү турында бригадалар һәм звенолар арасында үзара социалистик ярыш договорлары төзелде. Стена газеталары чыгарыла башлады.

Тикшерү вактында „Яңа Юл“ колхозында да күп кенә кимчелекләр ачылган иде. Рейд членнары Насыйбуллин, Әсәдуллин, Вафин, Низамов иптәшләр тикшерү нәтиҗәләрен правление утырышында, колхозчыларның гомуми җыелышында тикшерделәр. Бригадаларда производство киңәшмәләре үткәрелеп, җитешсезлекләрне бетерү өчен конкрет чаралар билгеләнде. Нәтиҗә монда да начар түгел:

орлыкларны яровойлаштыру өчен урын хәзерләнде. Бәрәңге яровойлаштыруга салынды. 4 һәм 6 нчы бригадаларда звенолар төзелде һәм аларга участкылар беркетелде. Рейд бригадасы стена газеталарын чыгаруга аеруча игътибар бирде. Стена газеталары редакторлары белән киңәшмә үткәрелде.

„Кызыл Орден“, „Үзәк“ һәм Куйбышев исемендәге колхозлардагы рейд бригадалары да зур тырышлык белән эшлиләр.

М. Хәмидуллин.

РЕЙД БРИГАДАСЫ БАРГАЧ

БАЛТАЧ. **(Телефон буенча).** Хәбәрчеләрдән Сабиров, Фатыйхов, Хәкимов, Хөсәенев һәм Миңнекәева иптәшләр составында рейд бригадасы „Кызыл Татарстан“ колхозының язгы чәчүгә хәзерлеген тикшерде.

Бу колхоз бөртекле культураларның һәр гектарыннан кимендә 100 пот иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алып, „Кызыл Яшьләр“ колхозын социалистик ярышка чакырган. Шул ярыш нигезендә бригадалар арасында да договорлар төзелгән һәм аларның үтәлеше системалы рәвештә тикшерелеп барыла. Социалистик ярышны киң җәелдерү нәтиҗәсендә колхоз быел кышкы агрономия чаралары планнарын арттырып үтәүгә ирешкән. Мәсәлән, кырга тирес чыгару буенча еллык план 144 процент, көл җыю планы 110 процент, кош тизәге хәзерләү планы 205 процент үтәлгән.

Колхозда даими 28 звено оештырылган. Чәчү машинасында эшләү өчен иң оста машинистлар билгеләнгән. Чәчүлек орлыклар яхшы урыннарда сакланалар. Каравылчы иптәш Гаффаров орлык амбарларын сизгер саклый. Ә агротехник иптәш Гарифуллин орлыкларның торышын даими рәвештә тикшереп бара.

Атларны язгы чәчүгә хәзерләүдә ат караучылардан иптәш Гатауллин башкаларга яхшы эш үрнәге күрсәтә. Ул тәрбияли торган атлар көр һәм тазалар. Ул, атларны аларның зурлыкларына һәм язгы чәчү вактында нинди эш башкаруларына карап группаларга бүлеп тәрбияли.

Рейд бригадасы колхозның 1 нче һәм 4 нче кырчылык бригадаларында атларны язгы чәчүгә хәзерлекне канәгатьләнерлек түгел дип тапты. Моның төп сәбәбе ат караучыларның еш кына алмашынып торуларында икәнлеге беленде.

Колхоз быел 200 гектар мәйданда яровойлаштырылган орлык чәчәргә тиеш. Хәбәрчеләр бригадасы килгәндә бу эшкә бернинди хәзерлек юк иде дип әйтерлек. Бригада бу кимчелекнең шул көнне үк бетерелүенә ирешә: яровойлаштыру өчен бина хәзерләнде, мичләргә ремонт ясалды.

Бригада килгәндә язгы чәчү өчен кирәкле арбалар да хәзер түгел иде. Хәбәрчеләрнең тәкъдиме буенча колхоз правлениесе арбаларга ремонт ясауны оештырды. Колхозда производство планы төзелгән. Ләкин ул колхозчыларның гомуми җыелышына куелмаган иде. Хәбәрчеләр баргач план колхозчыларның гомуми җыелышына куелды һәм шунда ук нормалар да тикшерелде.

Х. Галләмев.

Тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты СВОДКАСЫ

1940 нчы елның 5 нче апреленә
(Планга карата процентларда)

МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш	МТС лар	Үтәлеш
Төньяк районнар:		Куйбышев	96,0	*Көнбатыш районнар:*	
Нөркәй	100,0	Мөслим (Чистай)	95,8	Кама Тамагы	100,0
Теләче	100,0	Биләр	93,6	Юртыш	100,0
Маткавыш	100,0	Каргалы	89,3	Дәүләки	100,0
Актаныш	100,0	Кузнечиха	87,0	Чүпрәле	100,0
Мөслим	100,0	Алексеевский	86,4	Ишеево	100,0
Янил	100,0	Әлки	86,0	Тархан	97,7
Алга	100,0	Базарлы Матак	85,2	Майдан	96,8
Кадрәк	100,0	Иске Тимошкино	82,9	Буденный	96,4
Тирсә	100,0	Трехозерский	80,0	Столбище	94,5
Т. Тамак	100,0	Салман	79,4	Чокалы	92,7
Минзәлә	100,0	Тат. Ялтан	77,8	Биектау	92,5
Азин	100,0	Чишмә	74,5	Олы Кариле	91,9
Балтач	100,0	Яңа Чишмә	73,3	Мәлки	91,7
Чаллы	100,0	Кошкино	72,5	Питрәч	91,1
Исәнбай	100,0	Тельман	72,0	Норлат	89,1
Кукмара	100,0	Ромадан	65,9	Буа	88,4
Тәкәнеш	100,0	Барлыгы	87,3	Тәтеш	86,5
Бондюг	97,7	*Көньяк-көнчыгыш районнар:*		Макыл	86,3
Алабуга	92,7	Тымытык	100,0	Әлши	85,7
Этнә	90,0	Әлмәт	100,0	Мөрәле	83,7
Калинин	88,9	Беренче Май	100,0	Дөбъяз	83,3
Саба	88,6	Сарман	100,0	Тат. Ходяш	83,3
Арча	88,2	Чалпы	100,0	Юдино	80,9
Кызыл Йолдыз	85,5	Кичү	100,0	Әхмәмәт	77,3
Морт	85,1	Кәкре Елга	100,0	Чүрибураш	76,3
Балык Бистәсе	84,2	Шөгер	98,0	Зөя	71,8
Мамадыш	83,3	Ютазы	96,3	Константиновский	78,7
Кызыл Юл	78,0	Акташ	92,6	Рождественский	62,3
Димитровский	60,6	Иске Писмән	92,6	Барлыгы	86,6
Барлыгы	93,3	Чыбыклы	88,5	МТС лар буенча барлыгы	88,7
Кама арты районнары:		Чишмә	83,3	1940 нчы елның 1 нче апреленә	86,1
Черемуховский	100,0	Үзәк	80,8	1939 нчы елның 5 нче апреленә	93,5
Иске Чишмә	100,0	Баулы	78,1		
Аксубай	100,0	Соколка	77,8		
Кызыл Чапчак	100,0	Поповка	77,6		
Октябрь	100,0	Бөгелмә	70,7		
Зирекле	100,0	Заинский	64,7		
Зур Поляна	97,6	Кузайкино	63,5		
Чистай	96,7	Карамалы	61,2		
		Барлыгы	86,6		

Орденлы Актаныш МТС ында. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): тракторчылар курсы курсантларыннан С. Саматова, М. Заһриева һәм М. Закирова иптәшләр трактор моторын өйрәнәләр.
А. Михайлов фотосы
(ТатТАСС фотохроникасы).

ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕ

Сай сөрәләр

(Үз хәбәрчебездән)

ӘЛМӘТ, 9 апрель. **(Телефон буенча).** 8 нче апрельдә „Ярыш“ колхозының барлык бригадалары да өлгергән участкыларны сайлап сөрү һәм туңга сөрелгән җирләрне тырмалау эшләрен башладылар. 14,5 гектар җир сөрелде һәм 12 гектар җир тырмаланды. 4 нче бригада членнарыннан Мортаза Маликбаев, Шәйхулла Яруллин иптәшләр беренче көнендә үк норманы 110 процент үтәделәр.

„Ирек“ колхозында 3 гектар җир сөрелде. Ләкин монда эшнең беренче көне сыйфат өчен көрәш җитәрлек булмавын күрсәтте. Бары 12—13 сантиметр тирәнлеккә сөрделәр.

„Дирижабль“ һәм Буденный исемендәге колхозларда җирләрнең өлгерүен күзәтеп тору өчен дозорлар билгеләнде.

З. Салахеттинов.

Тракторлар белән сөрү башланды

МӨСЛИМ, 9 апрель. **(Телефон буенча).** Районда язгы кыр эшләре башланды. „Ялкын“ колхозы бу эшкә беренче булып керешә. Эшнең беренче көнендә үк нормалар арттырып үтәлде. Сафа Камалов, Зарифулла Рахманов, Мәҗит Саттаров һәм Кәримев иптәшләр норманы 150 процент итеп үтәделәр.

„Җиңәр“, „Путиловец“, „Корыч кул“, „Динамо“ һәм башка колхозларда да өлгергән участкыларны сайлап сөрү һәм тырмалау башланды.

Бүген Мөслим МТС ының 5 тракторы сөрү эшләренә керешә.

Шәйми.

ЭШКӘ, УЧАСТКЫГА!

ЧИСТАЙ, 8 апрель. **(Телефон буенча).** Чистай шәһәре буйлап бер-бер артлы 4 трактор үтеп китте. Болар Александр иптәш Мурашев отрядындагы тракторлар. Алар барсы да „Красный Пролетарий“ колхозына баралар.

Тракторчылар „Красный Пролетарий“ колхозына барып җитү белән правление членнары һәм колхоз активлары белән берлектә киңәшмә үткәрелде. Киңәшмәдә колхоз белән Чистай МТС ы арасында төзелгән договорның аерым пунктлары тикшерелде. Правление тарафыннан үтәлмәгән эшләрне тормышка ашыру өчен конкрет чаралар билгеләнде.

Колхоз трактор бригадасында аш пешерү өчен күчмә кыр кухнясе, утын, аш тарелкалары, мискиләр, кашыклар, чәнечкеләр, пычаклар хәзерләгән. Культвагон трактор бригадасы эшләячәк участкыга чыгарылды. Вагонда газета-журналлар, авыл хуҗалыгы китаплары, аларны кую өчен махсус шкаф, лампа, шахмат, домино һәм башка төрле кирәк әйберләр бар. Стена газеталары өчен макетлар, карандашлар, каләмнәр, 5—6 төрле буяу хәзерләнгән.

Бригадада масса-политик эшләрне алып бару өчен 3 кеше билгеләнгән. Александр иптәш Мурашев бригадасы һәр тракторга иң кимендә 800 гектар эшләү, ягулыкка 10 процент һәм запас частьләргә 5 процент экономия ясау һәм тракторларны эш сезоны беткәннән соң төзек килеш тапшыру йөкләмәсен алып, Александр иптәшнең кече туганы Михаил иптәш Мурашев бригадасын социалистик ярышка чакырды. Иптәш Михаил бригадасы бу бригаданың чакыруын тулысынча кабул итте.

Бригада планы буенча бөртекле культуралар чәчү 6 эш көнендә төгәлләнергә тиеш. Һәрбер трактор ике смена эшләячәк. Бригадада берничә номер стена газетасы чыгарылды. Хәзер участкыда туфракның өлгерүен тикшерү буенча махсус дозорлар тора.

К. Исламов.

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ ДОГОВОРЛАРЫНЫҢ ҮТӘЛЕШЕН ТИКШЕРӘЛӘР

Саба МТС ы Азин МТС ы белән ярыша. Ярыш договорының үтәлешен тикшерү буенча Саба МТС делегациясе Азин МТС ында булды.

Делегация Азин МТС ының язгы чәчүгә хәзерлек буенча күп кенә эш тәҗрибәләрен өйрәнде. Язгы чәчү өчен кирәкле машиналарга ремонт ясау вактында һәм оешкан рәвештә үткәрелгән. Колхозлар белән МТС арасында договорлар төзелгән. Трактор бригадалары кадрлар белән тулысынча комплектовать ителгәннәр.

МТС та кадрлар хәзерләүгә нык әһәмият бирелә. 15 хатын-кыз производстводан аерылмыйча тракторчылар хәзерләү курсларында укыйлар.

Шуның белән бергә делегация язгы чәчүгә хәзерлектә МТС ның кимчелекләрен дә күрсәтте. 2 тракторга ремонт төгәлләнмәгән әле. Шулай ук ремонтланган 36 тракторның 6 сы начар сыйфатлы итеп эшләнгән. ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Совнаркомының трактор станцияләренең эшләре һәм тракторлардан файдалану турындагы карарларын популярлаштыру һәм аларны практик тормышка ашыру өчен көрәш һич тә җитәрлек түгел.

Язгы чәчүгә хәзерлек буенча МТС ның колхозларга җитәкчелек итүе начар һ. б.

Азин МТС коллективы делегация тарафыннан күрсәтелгән кимчелекләрне кичекмәстән бетерергә сүз бирде һәм аларны бетерү турында конкрет эшкә керешә.

Агроном ***Гыйлаҗев.***

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Уңышлы башлангыч

Әлмәт районы, Кәшер авылындагы башлангыч оешмада булып үткән отчет-сайлау җыелышы, оешманың эшендә уңышлы яклар белән бергә, зур гына җитешсезлекләр дә булуын күрсәткән иде. Күрсәтелгән кимчелекләрне тизлектә бетерү өчен партия оешмасына, барыннан да элек, колхоз производствосына җитәкчелекне кискен рәвештә көчәйтү кирәк булды. Без эшне әнә шуннан башладык та. Барлык бригадирлар да партия җыелышында расландылар. Шуның нәтиҗәсендә бригадирлар эштә үзләренең җаваплылыкларын ныграк сизә башладылар. Партия оешмасы белән аларның бәйләнешләре тагын да ныгыды.

Партия оешмасы колхоз кадрлары белән системалы рәвештә киңәшмәләр уздыра һәм алдынгыларның эш тәҗрибәләрен урталашуны оештыра башлады. Бу чаралар колхозның производство эшләрен сизелерлек яхшыртуга китерде. Мәсәлән, күптән түгел бригадир итеп күтәрелгән комсомолка Җәләева һәм Әхметова иптәшләрнең бригадаларын комиссия язгы чәчүгә яхшы хәзерләнгәннәр дип тапты.

Агитколлектив членнарын яңадан сайлап алу үткәрелде, һәм хәзерге вакытта агитаторлар көче белән ВКП(б) ның XXI нче өлкә конференциясе СССР Верховный Советының Алтынчы Сессиясе материалларын хезмәт ияләре арасында өйрәнү эшләре җәеп җибәрелде. Отчет-сайлау җыелышы шулай ук стена газеталарына җитәкчелекнең йомшак булуын күрсәткән иде. Партия оешмасы барлык бригадаларда да яңадан редколлегияләр сайлау үткәрде. Редколлегияләр составына иң яхшы стахановчылар һәм ударниклар сайландылар. Шуннан соң һәр бригадада өчәр номер стена газетасы чыгарылды. Бу газеталарда язгы чәчүгә хәзерлек мәсьәләләре аеруча тулы яктыртылды.

Авылдагы 19 укытучы укый-яза белмәүчелекне Татарстанның XX еллыгына тулысынча бетерү буенча социалистик йөкләмә алганнар иде. Укырга тиешле 193 кешенең хәзерге вакытта 183 е занятиеләргә системалы рәвештә йөриләр. Укытучылардан Идрисова, Миргалимов, Ситдикова иптәшләр бу эштә аеруча зур тырышлык күрсәтәләр.

Партия оешмасы секретаре
Ахметов.

Кадрлар һәм алар белән эшләү

Партиянең XVIII нче съездыннан соң ВКП(б) ның Кукмара райкомы кадрлар сайлап алу һәм аларны тәрбияләү буенча үзенең эшен сизелерлек дәрәҗәдә яхшыртты, 100 дән артык кеше партия, совет һәм хуҗалык оешмаларына җитәкче эшләргә күтәрелде.

Шулардан ВКП(б) райкомы аппаратына 7, ВЛКСМ райкомы аппаратына 6 һәм район советы башкарма комитетына 7 кеше күтәрелде. Мәсәлән, Нархозучетның участкы инспекторы иптәш Павлов ВКП(б) райкомы инструкторы итеп, ВЛКСМ райкомының физкультура-хәрби бүлеге мөдире иптәш Насыйбуллин Осоавиахимның район советы председателе итеп һәм күптән түгел генә рядовой колхозчы булган орденлы иптәш Хәмидуллин район сәүдә бүлеге мөдире булып күтәрелделәр.

Алдынгы колхозчылардан 35 кеше авыл советы председательләре һәм секретарьлары итеп сайландылар. Шулай ук колхозлар өчен дә күп кенә яңа һәм эшкә сәләтле кадрлар сайлап алынды.

Кадрларга практик ярдәм күрсәтү эше дә шактый яхшырды һәм яшь кадрларның күбесе үзләренә йөкләнгән эшләрне уңышлы рәвештә башкарып киләләр. Мәсәлән, Янил һәм Кукмара МТС ларында ремонт эшләренең барышы турында райком бюросы МТС җитәкчеләренең докладларын тыңлагач, бу эштә булган төп җитешсезлекләрне күрсәтеп, аларны тизлектә бетерү өчен практик чаралар билгеләгән иде. Нәтиҗәдә, Янил МТС ы тракторларга һәм тагылма инвентарьларга ремонт эшен срогыннан элек (февраль аенда ук) югары сыйфат күрсәткечләре белән төгәлләүгә иреште. Кукмара МТС ы ремонт эшендә өзеклектә иде. Райком бюросы күрсәтмәләре нигезендә һәм якыннан булышу нәтиҗәсендә эштә җидди борылыш ясалды. Бу МТС буенча да тракторларга ремонт эше уңышлы башкарылды.

Узган ел гына колхоз председателе булып эшли башлаган иптәш Әхәтовның язгы чәчүгә хәзерлек эшенә оператив җитәкчелек итүе һәм колхозчылар арасында политик-масса эшләрен яхшы оештыруы нәтиҗәсендә „Электро“ колхозы язгы чәчүне яхшы хәзерлек белән каршылый. Бу колхоз, орлыклары җитмәүче колхозларга 600 центнер орлык биреп ярдәм итте. Район советы депутаты иптәш Могыйнова җитәкчелек итә торган „Берлек“ колхозы чәчүгә хәзерлекне срогыннан элек һәм яхшы сыйфат белән төгәлләде.

Кадрларны үстерү һәм тәрбияләү мәсьәләсе белән райком бик яхшы шөгыльләнә дип әйтеп булмый әле. Югарыда китерелгән фактлар—алар, башлангыч уңышлар гына. Райкомга кадрлар белән эшләүне тагын да яхшыртырга, эшкә яңа күтәрелгән кадрларның эш тәҗрибәләрен урталашуны һәм системалы рәвештә аларның киңәшмәләрен үткәрүне оештырырга кирәк.

Г. Сезаев.
ВКП(б) райкомының кадрлар буенча секретаре

„Ширпотреб“ артелендә ВКП(б) га яңа керүчеләр түгәрәктә партия тарихын өйрәнәләр.
И. Галиев фотосы.

АГИТАЦИЯ ЭШЕНӘ ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕ ЯХШЫРТЫРГА КИРӘК

14 нче төзү тресты партоешмасында булып узган отчет-сайлау җыелышларында, партбюроның иске составын агитация эшенә начар җитәкчелек иткән өчен коммунистлар бик нык тәнкыйтьләделәр. Бу тәнкыйть бик урынлы иде. Чөнки хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар узганнан соң, партия оешмасы агитация-масса эшләре белән бөтенләй шөгылләнмәгән.

Партбюроның яңа составы, аерым алганда аның секретаре иптәш Королев, отчет-сайлау җыелышындагы бу тәнкыйтьтән һәм күрсәтмәләрдән үзенә тиешле нәтиҗәне ясарга һәм агитация-масса эшләрен юлга салу эше белән большевикларча шөгылләнергә тиеш иде. Әлегә моның булганы юк. Дөрес, партбюро агитаторлар составын яңадан карады һәм аларны аерым участкыларга беркетте. Ләкин шуннан соң алар турында тагын онытты.

Партия оешмасының 1 нче апрельдә булган җыелышында агитколлектив җитәкчеләре Ефимов һәм Кобенячкин иптәшләрнең докладлары тыңланды. Иптәш Ефимов җитәкчелек итә торган агитколлективта 16 агитатор бар. Бу агитаторлар Свердлов исемендәге поселокның элекке 4 нче сайлау участкысында 18 беседа уздырганнар. Беседаларда 270 кеше катнашкан. Күп кенә агитаторлар чын-чынлап эшкә башлаганнар. Агитаторлардан Черемисских, Ханина һәм Девятов иптәшләр аеруча яхшы эшлиләр.

Җыелышта чыгып сөйләүче агитаторлардан Яшков, Вилова һәм Черемисских иптәшләр үзләренә агитколлектив җитәкчеләренең булышмауларын, аерым мәсьәләләр буенча инструктажлар бирелмәүне һәм агитаторларның эшләренә бер нинди дә контрольнең булмавын ачык фактлар белән күрсәттеләр. Мәсәлән, агитатор итеп билгеләнгән коммунистлардан Козлов, Леонтьев һәм Исхаков иптәшләр әлегә кадәр бер нинди дә эш алып бармаганнар. Ә партбюро бу коммунистларның үзләренә тапшырылган партпоручениене ничек үтәүләрен бер тапкыр да тикшермәгән.

Җыелыш, элекке сайлау участкыларында агитация эшенең канәгатьләнмәслек торуын тагын бер тапкыр күрсәтеп үтте. Партбюро үзенең эшендәге бу кимчелекне ашыгыч рәвештә төзәтергә, агитация-масса эшенә көндәлек җитәкчелекне һәм контрольне тәэмин итәргә тиеш.

Д. Прокофьев.

МӘКТӘП КОМСОМОЛ ОЕШМАСЫ

Чүпрәле районы, Чүпрәле урта мәктәбе янындагы комсомол оешмасы яхшы гына эшләп килә. Комсомолецлар һәм укучылар арасында политик-тәрбия эше киң җәелдерелде. Комсомол сафларына алдынгы укучыларны тарту эше яхшы бара. Уку елы башыннан алып хәзергә кадәр 40 укучы комсомолга кабул ителде. Оешмада барлык эш планлы рәвештә алып барыла. Күп кенә комсомолецлар „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән һәм кайберләре түгәрәкләргә йөреп өйрәнәләр.

ВЛКСМ членнарының барсына да диярлек поручениеләр бирелгән. Поручениеләрнең үтәлеше системалы рәвештә тикшерелә.

Комсомолецлардан Хисмәтов, Сафин, Гурмин һәм Нигмәтуллина иптәшләр уку отличниклары булып саналалар. Алиакберов һәм Азмуханов иптәшләр комсомол сафларына кергәч, үзләренең уку сыйфатларын тагын да яхшырттылар.

Н. Фәтхуллин.

Санитария-оборона эшен яхшыртырга

СССР Кызыл Хаҗ җәмгыяте союзының башкарма комитеты 1940 нчы елгы авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә катнашу турында карар бирде. Күргәзмәдә Кызыл Хаҗ җәмгыятенең колхозлар янындагы башлангыч оешмаларының, санитария постларының, санитария-оборона эше инициаторларының яхшы эш үрнәкләре күрсәтеләчәк.

Татарстан колхозлары янында хәзер РОКК ның 550 башлангыч оешмасы бар. Аларда 13.629 кеше член булып тора. ГСО значкистлары 4.730 лап санала. РОКК оешмалары, аерым алганда һәм бигрәк тә колхозлар янындагы оешмалар, күргәзмәдә катнашу хокукын яулап алу өчен көрәшне киң җәелдерергә тиешләр. РОКК ның район комитетлары һәм башлангыч оешмалары, шулай ук санитария постлары арасында социалистик ярышны киң җәелдерү нигезендә республикабыз колхозларында, совхозларында һәм МТС ларында санитария-оборона эшен үрнәк булырлык итеп куярга кирәк.

Бу эштә ВКП(б) ның район комитетлары, аларның хәрби бүлекләре, башлангыч оешмалар, комсомол, профсоюз оешмалары һәм медицина работниклары РОКК оешмаларына якыннан торып булышлык күрсәтергә тиешләр.

Хезмәт ияләре арасында патриотик хәрәкәтне тагын да киңрәк җәелдерү һәм аны бер яклап үстерү, һәрбер колхозда, совхозда һәм МТС та РОКК ның башлангыч оешмасын һәм санитария постларын булдыру һәм аларны ныгыту, членнар санын максималь рәвештә үстерү, ГСО һәм БГСО значкистларын хәзерләү, РОКК членнары арасында үрнәк дисциплина булдыру, членлык взнослары вакытында һәм тулысынча түләнүен тәэмин итү—бурыч әнә шундый.

ВКП(б) райкомнары, аларның хәрби бүлекләре, комсомол һәм профсоюз оешмалары РОКК оешмаларының эшенә конкрет җитәкчелек иткән урыннарда эш яхшы тора, башлангыч оешмаларның һәм членнарның саны үсә, РОКК членнары арасында дисциплина яхшы. Санитария-оборона эшен ныгыту һәм тагын да җәелдерү буенча Буденный, Заинский, Биектау, Ютазы, Чистай, Арча һ. б. районнардагы РОКК оешмалары яхшы эшлиләр. РОКК ның Чистай район комитеты (председателе иптәш Павлов) 1939 нчы елны гына да районда 33 башлангыч оешма төзеде. РОКК членнары итеп яңадан 2.258 кеше алынды, 5.830 сум членлык взнослары җыелды.

РОКК эше үрнәк рәвештә оештырылган колхозлар һәм предприятиеләр бездә аз түгел. Тәтеш районы колхозлары РОКК оешмалары Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең XXII еллыгына районнарда призывникларның 80 процентын ГСО ның беренче баскыч значкистлары итеп, 69 кешене икенче баскыч значкистлары итеп хәзерләделәр. Акташ районының Илбута авылында ГСО түгәрәге оештырылды. Түгәрәкне РОКК активисткасы иптәш Куприянова җитәкчелек итә. Түгәрәкнең бер группасында гына 25 кеше укый. Түгәрәктә катнашучылар санитария-оборона белемнәрен тирән кызыксыну белән өйрәнәләр, аларның барсы да—РОКК членнары.

Алдынгылар белән бергә, санитария-оборона буенча канәгатьләнерлек эшләмәүче, хурлыклы рәвештә артта калучы оешмалар да бар. Бу, бигрәк тә Алексеевский, Югары Ослан, Дөбъяз, Питрәч, Мамадыш һ. б. күп кенә районнарның РОКК оешмаларына кагыла. РОКК ның бу районнардагы оешмалары ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын үзләре өчен тиешле программа итеп алмадылар. Алексеевский районында (РОКК ның район комитеты председателе Петроградский, ВКП(б) райкомының хәрби бүлеге мөдире Сорокин) 1939 нчы елны бары бер генә башлангыч оешма төзелгән. Яңадан кабул ителгән членнарның саны да аз. Членлык взнослары вакытында түләнми.

Производстводан аерылмыйча Кызыл Армия өчен запас медицина сестралары хәзерләү эше дә әле тиешле югарылыкта тормый. РОКК ның Татарстан Өлкә Комитеты медицина сестраларын хәзерләү буенча Казан шәһәрендә 15 урында курслар оештырды. Алар күбесе югары квалификацияле укытучылар, дәресләр һ. б. кирәк-яраклар белән яхшы тәэмин ителделәр. Ләкин занятиеләрнең барышын канәгатьләнерлек дип әйтеп булмый. Кайбер урыннарда, мәсәлән, Педагогия институтында, партия, комсомол һәм профсоюз оешмаларының җитәкчеләре һәм администрация курсларның эшенә тиешенчә игтибар итмиләр. Курсларның кайберләрендә, мәсәлән, 2 нче тегү фабрикасы янында оештырылган курсларда курсантлар арасында политик-масса эше алып барылмый. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Алар күп кенә урыннарда санитария-оборона мәсьәләләренә игътибарның әле җитәрлек булмавын күрсәтәләр. Мондый җитешсезлекләр кичекмәстән бетерелергә тиеш.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукын яулап алу өчен РОКК оешмалары үзләренең эшләрен кискен рәвештә яхшыртырга тиешләр.

Г. Камалеттинов.

Финанс эшенә игтибарны көчәйтергә

СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе тарафыннан 1940 нчы ел өчен кабул ителгән дәүләт бюджеты илебезнең гаять зур уңышларын чагылдыра. 1940 нчы ел бюджетының доходлар өлеше 188 миллиард 585,9 миллион сум, расходлар өлеше 179 миллиард 710,9 миллион сум күләмендә расланды. Шул исәптән Ватаныбызның оборонасын ныгыту эшенә 57 миллиард 66,2 миллион сум билгеләнде.

1940 нчы ел бюджетын барлык совет халкы зур шатлык һәм тирән канәгатьләнү белән каршылады. Чөнки бюджетта каралган чаралар халык хуҗалыгын һәм культура төзелешен тагын да үстерүне, илнең оборонасын тагын да ныгытуны, совет халкының тормышын тагын да яхшыртуны тәэмин итүгә юнәлдерелгәннәр. 1940 нчы ел бюджетының әһәмияте аеруча зур һәм ул барлык финанс эшен тамырыннан яхшыртуны таләп итә.

Ләкин Татарстан АССР ның күп кенә районнарында финанс планы үтәлешенең торышы бүгенге сорауларга һич тә җавап бирерлек түгел әле. Республикада барлык төр түләүләр буенча беренче квартал планы 87,2 процентка гына үтәлде. Калинин, Кызыл Армия, Мөслим, Чепья, Ютазы, Сарман, Кызыл Юл, Ворошилов районнары финанс туплау буенча беренче квартал планын арттырып үтәүне тәэмин иттеләр. Ә инде Чүпрәле, Алабуга, Тельман, Әлки, Дөбъяз районнарында квартал планының үтәлеше 55—65 проценттан артмады. Бу районнарда финанс эшенә тиешле игтибарны биреп җиткермәү хәзергәчә дәвам итә.

Финанс планының срогында үтәлүе өчен, барыннан да элек финанс органнары җаваплы. Ләкин, байтак кына финанс работниклары бу таләпне әле дә булса аңлап җиткергәннәре юк. Өстебезгә алган йөкләмәләрне үтәү өчен көрәш һич тә канәгатьләнерлек түгел. Башкыртстан республикасы белән ике арада төзелгән ярыш договорының безнең тарафтан үтәлмәве моның ачык мисале. Ә ярышта без „һәрбер районда, барлык түләүләр буенча һәр кварталның финанс планын ун көн алда үтәргә“ дигән йөкләмә алган идек бит. Бу йөкләмә барлык район финанс бүлекләре, мөдирләре, барлык район саклык кассалары мөдирләре катнашы белән үткәрелгән актив киңәшмәсендә кабул ителде. Бу йөкләмә районнар арасында төзелгән ярыш договорларында да беренче пункт итеп кертелде. Кыскасы, вагдәләр бирүдә юмартлык аз булмады. Тик менә кайбер финанс работниклары йөкләмәләр алу белән генә тынычланмаска, ә ул йөкләмәләрне үтәү өчен большевистик көрәш оештырырга кирәклекне онытталар. Алар, хәтта үзләренә закон буенча йөкләнгән минималь бурычларны үтәү өчен дә тиешле чараларны күрмиләр.

Моңа мисаль итеп Буденный районын алырга мөмкин. Монда финанс работниклары планны срогыннан элек үтәү турында тантаналы вагдәләр бирсәләр дә, социалистик ярышны чын мәгънәсе белән оештыру турында уйлап та карамыйлар. Район финанс бүлеге мөдире Фәхреттинов, саклык кассасы мөдире Васильев, Госстрахның өлкән инспекторы Игошин иптәшләр социалистик ярыш турында сөйләнеп йөрү белән генә чикләнәләр. Финанс работникларының берсе дә индивидуаль рәвештә ярышмый. Яхшы эшләүчеләрнең эш тәҗрибәләре башкаларга күчерелми. Җитәкче работниклар үзләре эштә җавапсызлык күрсәтәләр. Район саклык кассасы мөдире иптәш Васильев Альшеево авылына барып, атналар буе торуына карамастан, тиешле борылышны тәэмин итмичә кайта. Финанс работниклары союзы месткомы председателе иптәш Андреев, өлкән инспекторлар Хәйруллин һәм Игошин иптәшләр беркетелгән участкылар финанс туплау буенча иң артта баралар.

Социалистик ярыш договорының үтәлеше турында сорау бирсәң, Буденный районының финанс работниклары: „Безнең район планны үтәмәсә дә, Тархан районыннан алдарак бара әле, без Тархан белән ярышабыз бит“ дип җавап бирәләр. Башкаларның артта калуына канәгатьләнү һәм үзеңнең начар эшең белән тынычлану социалистик ярышның эчтәлеген аңламау дигән сүз. Мондый караш хезмәт дисциплинасын йомшартуга алып бара һәм эштә җавапсызлык тудыра. Социалистик ярышка мондый караш Чистай, Алабуга, Тельман, Чүпрәле районнарында да бар. Моңа кискен рәвештә чик куярга кирәк.

Без финанс аппаратының эшен яхшыртуга район оешмаларының ярдәме белән генә ирешә алабыз, әлбәттә. Ләкин кайбер районнарда бу ярдәм җитәрлек түгел. Мәсәлән, Чистай район советының башкарма комитетына һәм ВКП(б) райкомына районда финанс эшенә игтибарны көчәйтү турында ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Татарстан Совнаркомы тарафыннан махсус күрсәтмәләр бирелүгә дә карамастан, алар эшне яхшырту өлкәсендә шушы көнгә кадәр тиешле чараларны күрмиләр. Бу районда финанс эшенең торышы турында ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Татарстан Совнаркомы карары чыкканнан соң 10 ай вакыт үтте, ә эштә үзгәреш юк әле, район һаман да артта бара.

Финанс эшендәге иң зур җитешсезлекләрнең берсе—мәҗбүри түләүләр буенча недоимкалар булудан гыйбарәт. Недоимкаларны булдырмау өчен, бигрәк тә ялгыз хуҗалыкчыларга карата, законда билгеләнгән чаралар тиешенчә кулланылмый. Мәсәлән, Аксубай районында бер ялгыз хуҗалыкчы усал ният белән мәҗбүри түләүләрне үтәми. Моңа район финанс бүлеге дә, хәтта Наркомфиннан барган ревизор иптәш Зорин да чара күрмәгәннәр. Недоимкаларны булдырмауның политик әһәмияте зур. Аксубай, Октябрь, Чистай, Норлат, Тархан район финанс работниклары бу эштә дисциплинасызлык күрсәтәләр.

Күп кенә районнарда саклык кассаларының эше гадәттән тыш начар оештырылган. Хәзер саклык кассалары алдында аеруча әһәмиятле бурычлар тора. Май аенда өченче бишьеллык заемы (икенче ел чыгарылыш) облигацияләре буенча подписчиклар белән расчетлар төгәлләнәчәк. Авылда да, шәһәрдә дә җыеп аласы подписка сумасы зур әле. Заем буенча расчетларны хезмәт ияләренең заемга подписка вактында күрсәткән зур активлыкларына җавап бирерлек дәрәҗәдә яхшы сыйфат белән төгәлләргә кирәк.

1940 нчы ел бюджеты саклык кассаларында вкладлар сумасын 1 миллиард 800 миллион сумга арттыру бурычын куйды. Татарстан саклык кассаларының бу өлкәдә мөмкинлекләре чиксез зур. Соңгы бер ел эчендә генә дә Татарстанда вкладлар сумасы 5 миллион 600 мең сумга артты һәм барлыгы 48 миллионга җитте. Вкладлар сумасын тагын да үстерү өчен хезмәт ияләре арасында саклык кассаларының файдалы яклары турында аңлату эшләрен киң җәелдерергә кирәк. Безнең кайбер работникларыбыз вкладчикларның килүен канцеляриедә генә көтеп утырырга гадәтләнгәннәр. Мамадыш районында „Пятилетка“ һәм „Агробаза“ совхозларында саклык кассалары оештырылуга ярты ел вакыт үтүгә карамастан, ул кассаларда вклад туплау эше әле башланмаган да. Район саклык кассасы мөдире иптәш Логинов, финанс бүлеге мөдире иптәш Корнауховның моңа бер дә эчләре пошмый. Моны саклык кассалары идарәсеннән Мамадышка барып 15 көн торып кайткан иптәш Васильев та күрмәгән. Мондый кассалар Азнакай, Ютазы, Актаныш, Биләр, Алабуга, Кызыл Армия, Лаеш, Яңа Чишмә һәм Юдино районнарында да бар.

Бездә финанс планын үтәүдә артта баручы районнарга һәм финанс работникларына үрнәк булырлык, финанс эшенең барлык тармаклары буенча гүзәл нәтиҗәләр бирүче районнар, авыл советлары һәм йөзләрчә финанс отличниклары бар.

Чепья, Тымытык, Мөслим, Калинин һәм башка күп кенә районнарның финанс работниклары активистлар белән нык элемтә тоталар. Алар уңышлы тәҗрибәләрне киң рәвештә башкаларга күчерү юлы белән социалистик ярышны җәелдерүне көндәлек бурыч итеп куйганнар. Финанс эше буенча алдынгы районнарның уңышлары ВКП(б) райкомнарының һәм район советы башкарма комитетларының бу эшкә тиешенчә җитәкчелек һәм ярдәм итүләренең нәтиҗәсе.

СССР Верховный Советының VI нчы Сессиясе финанс эше турында бик мөһим законнар кабул итте. 1940 нчы ел бюджеты турындагы закон белән бергә, халыктан доходлар налогы алу турында, культура төзелеше җыемы һәм мәҗбүри окладной страхование турында яңа законнар чыгарылды.

Бурыч—барлык финанс работникларының, партия һәм совет оешмаларының һәм бөтен җәмагатьчелекнең бу законнарны тиешенчә тормышка ашыру өчен көрәшләреннән гыйбарәт. Халыкара пролетариат бәйрәме—Беренче Майны Татарстанның барлык районнарында финанс планын үтәү буенча иң яхшы күрсәткечләр белән каршылау бу көрәшнең беренче нәтиҗәсе булачак.

Мәҗбүри налоглар һәм страхование түләүләре буенча недоимкаларны барлык районнарда апрель аенда ук җыеп бетерү, үз ара салым сумаларын һәм заем взносларын тулысынча җыеп алу, саклык кассаларына вклад туплауны һәм ирекле страхованиене тиешле югарылыкка күтәрү, барлык чыганаклар буенча бюджетның доходлар өлешен тулысынча һәм үз вактында керүен тәэмин итү өчен большевистик көрәш җәелдерергә кирәк.

С. Шәрәфиев.

Татарстан АССР Финанс Халык Комиссары,
СССР Верховный Советы депутаты.

Даими кыр станы

Авылны кергәч тә колхозның ашлык амбарлары, терлекчелек фермалары, машина сарайлары кебек төзек каралтылары, мәктәп, уку өе, клуб һәм балалар бакчасы кебек культура учреждениеләре тезелеп киткән. Болар кечкенә бер шәһәрчек төсен алып тора. Бу корылмалар арасына кереп китсәң һәр кайда төзеклек, оста хуҗаларча оештыручанлык күзгә ташлана. Һәр нәрсә үз урынында. Боларны карап йөрүе үзе бер күңеллелек.

Син „Бүләк бул" колхозына читтән килгән кеше икәнсең, анда кемне генә очратсаң да:

— Колхозның кай төшләрендә булдыгыз, кыр станында булдыгызмы әле?—дигән сорауны бик еш ишетәсең. Язмы, көзме, кышмы бары бер биредә кыр станы телдән төшми һәм анда бер вакытта да эш туктамый. Без дә, колхоз белән бераз танышкач кыр станына киттек.

Басу капкасын чыккач та киң басу. Юлның һәр ике ягында зур-зур тирес өемнәре.

— Болары безнең ашлык кешелләре инде,—диде колхоз председателе иптәш Шәйхуллин. Һәм:

— Без бит басуга тирес чыгаруны бик оста оештырабыз. Менә кыр станына баргач күрерсең әле. Хәзер тиреснең кадерен беләбез инде,—дип өстәп куйды.

Чынлап та, алар тирес кадерен белгән өчен, һәр төрле җирле ашламалардан дөрес файдаланган өчен дә ел саен мул уңыш алалар, күп доход бүләләр. Үткән ел да барлык дәүләт йөкләмәләрен тулысынча үтәгәннән соң, чәчү орлыгы, фураж, страхфонд өчен җитәрлек ашлыкны бүлеп куйганнан соң һәр хезмәт көненә 3,3 килограмм бөртекле ашлык һәм 6 шар килограмм терлек азыгы бүлгәннәр. Моннан арткан ашлыктан 1.100 центнер орлык һәм 1.000 центнер фураж белән башка колхозларга ярдәм иткәннәр.

Колхозчылар быел тагын да мулрак иген уңышы алу һәм тагын да күбрәк доход бүлү өчен кышкы агротехника чараларын арттырып үтәгәннәр, язгы чәчү өчен кирәкле барлык нәрсәләрне алдан әзерләп куйганнар. [illegible] кыр станына куйганнар. Алар мул уңышны яулап алу өчен көрәшәләр.

Колхоз юртагы безне кыр станына тиз илтеп җиткерде. Мондагы—ашлык амбарлары, ат абзарлары, өсте ябулы ындыр табаклары, уку өе, торак йортлары—үзенә бер кечкенә хуҗалык. Колхоз председателе Шәйхуллин ни әйтә:

— Монсы ирләр торагы, монсы хатын-кызлар торагы. Менә монсы ашханә, монсы кухня, монсы уку өе,—ди, зур ак йортның бүлмәләрен бүлмә-бүлмә күрсәтеп чыкты.

— Монда кыр эшләре башлангач килсәң күрер идең! Кайтасың да килмәс инде. Кичләрен гармон, курай, патефон тавышлары яңгырап тора. Спектакль һәм концертлар да шушында була. Кино-картина да шушында күрсәтелә. Радио сөйләп тора. Уку өендә газета-журнал укыйсыңмы, китап укыйсыңмы, шашка-шахмат уйныйсыңмы—һәммәсе була,—дип, безне монда кыр эшләре башлангач килергә кызыктырып куйды һәм сүзендә дәвам итеп:

— Быел менә авыл белән ике арага телефон кертәбез. Чыбык белән баганалар хәзерләдек инде. Эш, Калинин районы элемтә бүлегенең аппаратны тизрәк бирүеннән генә тора. Колхозчылар өчен дә, үзебез өчен дә колхозга яки районга йомыш төшкән саен авылга кайтып йөрүе читен бит. Якын дисәң дә, 5 километр араны кайтып килгәнче байтак вакыт үтә. Эш өстендә вакытның бер минуты да алтын бит аның,—дип кыр эшләре вакытында кыр станының ничек булачагы турында ул безгә байтак нәрсә сөйләде.

Станда кызу эш кайный. Күп кенә колхозчылар ашыга-ашыга орлык тазарталар. Кайберләре атларга азык ташый, кайберләре басуга тирес чыгара.

Атлар караучы стахановчы Зәки ага Хәбибрахманов үзе карый торган Орловский нәселле тайларны утарга яки эчерергә чыгаргач та, аларның койрык чәнчеп уйнаулары, гел шаярып торулары өчен:

— Һай уңгырлары!,—дип аларны орышкансыман итә. Ә үзе аларның шаян булулары өчен шатлана, әлбәттә.

Кыр станы турында барган сүз колхоз правлениесенә кайткач та дәвам итте. Иптәш Шәйхуллин:

— Менә безнең үткән ел кыр станында кунып эшләүчеләр: машинист Мөхәмәдиев, Гөлсем Газеттинова һәм Шәйхуллин иптәшләр яз көне 10,4 гектар чәчү нормасын көн саен 13—14 гектар итеп үтәделәр. Машина белән уру нормасы көнгә 8 гектар урнына 10—11 гектар итеп үтәлде. Безнең беренче бригада кырда кунып эшләмәде. Шуның өчен бу бригадада язгы чәчү нормаларын үтәү 6—7 гектардан артмады. Кырда кунып эшләүнең әнә шул ягы да бар аның,—ди. Безнең сүзгә бишенче бригаданың бригадиры иптәш Сираев кушылды:

— Аннары аның бу ягы да бар бит әле. Безнең анда 100 баш [illegible] тәрбияләнә. Алар авылда тәрбияләнсәләр, аларга кыш [illegible] ашату өчен [illegible] китәр иде. Кышның ничек кенә [illegible] булмый. Аннары бу вакытында арган ат белән авылга кайт, тагын бар. Ул арада күпме эш үтәргә була, кырда кунып эшләгәндә,—дип, кыр станында [illegible]. Аннары:

— Анда безнең 1.000 центнер орлык ашлыгы һәм фураж саклана. Аны башта авылга ташып, аннары чәчү вакытында кире басуга ташып кара әле,—дип өстәде.

Кыр станы турында сүз озак кына барды. Без, барлык колхозларда да шушындый кыр станнары оештырганда нинди яхшы булыр иде, дигән фикергә килдек.

А. Вәлиев.

Беренче тегү фабрикасының 1 нче цехы стахановчысы Г. Исламова. Ул беренче квартал планын 176 процент итеп үтәде. И. Галиев фотосы.

ЯҢА ЭШЧЕЛӘРНЕ ТӘРБИЯЛӘҮ ҺӘМ ҮСТЕРҮГӘ ИГТИБАРНЫ КӨЧӘЙТИК

Промышленность предприятиеләре һәр елны меңнәрчә яңа эшчеләр кабул итәләр. ВКП(б) ның тарихы XVIII нче съездыннан соң, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин күрсәтмәләреннән соң, колхозлардан промышленностька эшкә килүчеләрнең саны тагын да артты. Предприятие җитәкчеләренең бурычы—яңа эшчеләрне тәрбияләү, аларның квалификацияләрен күтәрүгә һәм яклап булышлык итүдән, яхшы эш шартларын тудырудан гыйбарәт.

Бу эш дөрес һәм яхшы итеп оештырылган урыннарда яңа, яш кадрларның үсүе, тәрбияләү өлкәсендә шактый зур нәтиҗәләргә ирешелгән. Мәсәлән, Ленин исемендәге тегү фабрикасы җитәкчеләре [illegible] алый. Монда кадр эшчеләр, стахановчылар, мастерлар яш эшчеләрне эшкә өйрәтүгә, аларның квалификацияләрен күтәрүгә зур игтибар итәләр. Иптәш Евграфов сменасында эшләүчеләрдән Радионова, Власова, Галиева һәм Мәхмәтҗанова иптәшләр кыска гына вакыт эчендә уннарча яңа эшчеләрне квалификацияле эшкә өйрәттеләр. Нәтиҗәдә яңа эшчеләр стахановча эшләү методын үзләштерделәр һәм Егорова, Самигуллина, Тәхфәтуллина кебек байтак кына иптәшләр икешәр аппаратка хезмәт күрсәтә башладылар.

Серго Орджоникидзе исемендәге завод колхозлардан килгән яңа эшчеләрне тәрбияләүдә аеруча зур уңышларга ирешәтте. Бу заводта тулы мәгънәсе белән кадрлар чыныктыру мәктәбе. Заводта әле күптән түгел генә эшләүче Лигдриянов һәм Антонова иптәшләр хәзер мастер итеп күтәрелделәр һәм үз эшләрен намус белән башкаралар. Иптәш Михеев шлифовщик, иптәш Далауров фрезеровщик квалификацияләрен үзләштерделәр, [illegible] заводта [illegible]. 4 нче мех фабрикасының кисү цехы мастеры иптәш Гафиятуллина да производствога яңа килгән эшчеләрне эшкә өйрәтүдә үрнәк күрсәтә. Ул җитәкчелек итә торган участокта эшләүчеләрнең күпчелеге колхозлардан килгән яңа эшчеләр. Иптәш Гафиятуллинаның һәм участкы стахановчыларының зур тырышлык күрсәтүләре белән яңа эшчеләр эш төрләрен бик тиз үзләштерделәр һәм участкы хәзер тотал стахановча участкы булып әверелде.

Кызганычка каршы, яңа эшчеләрне тәрбияләү, аларның производство квалификацияләрен күтәрү эше һәр җирдә дә яхшы оештырылган дип әйтеп булмый әле. Кайбер предприятиеләрдә эшчеләрнең күчеп йөрүләре зур күләм алган. [illegible] Наркомат систематик предприятиеләрдә узган елны 12 мең 61 кеше эшкә алынган. Ә эштән китүчеләр саны 13 мең 162 кеше иде. Киез итек-фетр һәм 6 нчы номерлы тегү фабрикалары шикелле предприятиеләрдә бу хәл тагын да аянычрак. Казан шәһәрендәге киез итек-фетр фабрикасында соңгы 14 ай эчендә 3.772 кеше эшкә алынган булса, 3.213 кеше эштән киткән. Бу предприятие җитәкчеләре эшкә яңа алынган эшчеләрне эшкә ничек өйрәнүләре, аларны тәрбияләү эшенә торышы белән җитәрлек дәрәҗәдә кызыксынмыйлар, яш эшчеләрне производствога беркетү чаралары күрмиләр.

Урыннардагы партия, профсоюз, комсомол һәм хуҗалык оешмалары производствога квалификацияле кадрлар булдыруга һәм аларны тәрбияләүгә нык игтибар бирергә, бу әһәмиятле эшкә бәя биреп җиткермәү күренешләрен бетерергә тиешләр.

К. Халиков.

ВОЛГА КЕШЕЛӘРЕ

Куәтле буксирларга корыч баулар белән тагылган, авыр йөкләр төялгән баржаларның дулкыннарда тирбәлеп баруын күз алдына китерегез... Баржаларның һәм пароходларның трюмнарыннан меңнәрчә тонна йөкләрне тартып чыгаручы транспортерларның, ул транспортерларны хәрәкәткә китерүче моторларның һәм грузчикларның җырларын тыңлагыз. Иректе һәм шатлыклы хезмәт белән туган бәхет җырлары хәзер Волга буйларында көчле симфония булып яңгырыйлар.

***

Волга! Күп сулы, көчле һәм җитез карт Волга! Әгәр син тарихчы карт булса идең, элек синең ярларың буенда яш агыза-агыза баржа тарткан бурлакларның кайгылы җырларын безгә сөйләгән булыр идең. Арканнар белән җилкәләре суелган, яр ташларына аяклары уелган, ярым ач, ярым ялангач бурлакларның безгә килеп җиткән җырлары бик күп нәрсә турында сөйлиләр. Ул җырлар ачы-хәсрәт һәм офтану җырлары иде. Бу төшенкелек җырлары хәзер яңа, дәртле җырлар белән алмаштырылды:

Волгадай гайрәтле көчлебез,
Байлыкны тудырган кешебез,
Хурлыкны, коллыкны җимереп
Бәхетле яңа ил төздек без...

Бөек илнең бөек елгасы Волга! Хәзер синең суларыңа кешеләрнең күз яшьләре кушылмый. Синең өстеңдә ишкәк ишкән элекке колларның һәм ярларың буенча баржалар тарткан бурлакларның балалары яңа баскычка, ил белән идарә итү баскычына күтәрелделәр. Синең ярларың буенда азат хезмәтне мактаган җырлар һәм моторлар тавышы яңгырый. Синең өстеңдә йөзүче ак пароходлар хезмәт ияләренең ял итү урыннарына әйләнделәр.

Матур, горур Волга! Синең кешеләрең хәзер бөтенләй башкалар. Ялагай десятниклар да, Бугычевлар да хәзер юк инде. Синең кешеләрең үзләрен дан белән каплыйлар һәм синең даныңны үстерү өстендә эшлиләр. Обмотка мастеры Нурулла иптәш Зиннәтуллин әнә шуларның берсе.

Саба районының Түбән Утар авылындагы элекке күп сандагы ярлыларның берсе булган Зиннәтулла абзый семьядәге 6 кешене туйдыручы бердән-бер ир иде һәм бөтенләй диярлек җирсез иде. Ул көне-төне эшләсә дә, семьясен туйдыра алмый, һәм „ир бала тапмавы өчен" беренче хатыны белән аерылышырга мәҗбүр була. Шул ук вакытта Утар, Саба, Сатыш байлары 100 әр десятинә җир билиләр иде.

1904 нче елда Зиннәтулла абзый семьясендә ир бала туа. Аңа Нурулла дип исем бирәләр һәм аның бәхет китерүенә өмет баглыйлар. Ләкин капитализм хөкем сөргәндә, ир бала туу белән генә тормыш җиңеләйми. Бу семья авыл кулакларына арзанлы кул көче бирүче семья була. Балалар яштән үк тамак ялына, кулакларның авыр эшләрен башкаралар. Нурулла да 10 яшеннән ялланып эшли башлый: җәйләрен көтү көтә, кышларын каравылда тора.

***

... 1931 нче елның август аенда Нурулла Зиннәтуллин Казан пристаненә килде һәм грузчик булып эшли башлады. Моторлар тавышы Зиннәтуллинны үзенә җәлеп иттеләр. Ул производстводан аерылмыйча, механизаторлар курсында укый һәм 1932 нче ел навигациясен электромонтер булып каршылый. Эшкә сәләтле һәм тырыш булу аркасында, ул моторларның барлык нечкәлекләрен өйрәнә һәм 1937 нче елда обмотка мастеры дәрәҗәсенә күтәрелә.

Зиннәтуллин Казан пристаненең атаклысы. Пристаньдә 9 ел эшләве чорында ул 13 тапкыр бүләкләнә, Елга Флоты Халык Комиссары аны исемләнгән сәгат белән бүләкли.

Елга флоты алдында торган җаваплы бурычларны уңышлы үтәү механизмнардан тулы файдалануга һәм Блидман методын тормышка ашыруга нык бәйләнгән. Механизмнарның төп өлеше—мотор хуҗалыгы. Икенче төрле итеп әйткәндә, йөк төяү-бушатуны механикалаштыруда мотор хуҗалыгы иң әһәмиятле урын тота.

Моторларга капиталь ремонт ясау тәмамланды. Ремонтның иң җаваплы өлешен,—обмотка ясауны ВКП (б) члены, Казан шәһәр советы депутаты иптәш Зиннәтуллин башкарды. Зиннәтуллин айлык заданиеләрне 150—200 процент итеп, ә эш белән тулысынча тәэмин ителгән көннәрдә норманы 350—400 процентка җиткереп үти. Саннан сыйфат калышмый. Зиннәтуллин ремонтлаган моторларның барсы да отлично билгесенә кабул ителделәр. Узган навигациядә обмотчик гаебе белән бер генә мотор да эштән туктамады. Зиннәтуллин исме пристань стахановчыларының почет тактасыннан төшми.

— Моторларны тулы тизлектә эшләрлек итеп хәзерләү—төп бурычларның берсе. Без бу бурычны үтәдек дип әйтәсе килә. Ләкин тулы сынау алда әле. Бу сынауда да без сынатмаска тырышырбыз һәм партия тарафыннан куелган бурычларны намус белән үтәрбез,—ди иптәш Зиннәтуллин.

... Тирән сулы, киң колачлы Волга! Әгәр син тормышта булган үзгәрешләрне хис итү һәм бу хисне белдерү куәтенә ия булсаң иде, бәхетле илнең бәхетле уллары һәм кызларының шатлыкларын уртаклашыр һәм хезмәтне намус эшенә, дан эшенә һәм геройлык эшенә әверелдергән алдынгы кешелек дөньясының титаннарын безгә кушылып зурлар һәм хөрмәтләр идең.

Хак Максуд.

Массалар белән элемтәне тагын да ныгыту өчен

Сталин Конституциясе халык судының районнардагы гражданнар тарафыннан гомуми, туры һәм тигез сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү тәртибендә сайлануын билгеләп, аның ролен һәм әһәмиятен зур политик югарылыкка күтәрде. Совет судьялә-ре халык тарафыннан сайланалар һәм халык алдында отчет бирәләр.

Халык суды—массага иң якын торучы суд. Уголовный һәм гражданский эшләрнең иң зур күпчелеге халык судында карала. Социалистик законлылыкны тормышка ашыру һәм гражданнарның хокукларын саклау эшендә халык судының эше гаять зур әһәмиятле урын тота. Халык судлары үзләренең эшендә, барыннан да элек, массалар белән, сайлаучылар белән нык элемтәдә булырга тиешләр.

1937 нче елны ВКП(б) Үзәк Комитетының февраль - март пленумында иптәш Сталин болай диде:

„Югарыдан тикшерү, кешеләрне тикшерүнең һәм заданиеләрнең үтәлүен тикшерүнең чын чараларыннан берсе булу сыйфатында, әлбәттә, кирәк. Ләкин югарыдан тикшерү, тикшерүнең бөтен эшен үз эченә алып бетерүдән ерак әле. Тагын икенче төрле тикшерү, түбәннән тикшерү яши, биредә массалар, җитәкләнә торган кешеләр, җитәкчеләрне тикшерәләр, аларның ялгышларын күрсәтәләр һәм ул ялгышларны төзәтү юлларын күрсәтәләр. Мондый төр тикшерү кешеләрне тикшерүнең иң чын юлларыннан берсе булып тора".

Халык судьяләренең сайлаучылар алдында отчеты судның эшен тикшерүнең иң чын юлларыннан берсе, массалар белән элемтәнең иң яхшы формаларының берсе булып тора.

СССР ның, союзный һәм автономияле республикаларның суд төзелеше турында закон (29 нчы статья) халык судьяләреннән үзләренең һәм халык судларының эше турында сайлаучылар алдында регуляр рәвештә отчет бирүне таләп итә. Татарстан АССР дагы судьяләрнең зур күпчелеге бу таләпне үтәп, халык алдында регуляр рәвештә отчет бирә. 1939 нчы елны халык судьяләре колхозларда, совхозларда, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм башка оешмаларда 822 отчет доклады ясадылар. Үткәрелгән җыелышларда хезмәт ияләреннән 60 мең кеше катнашты, судьяләрнең отчет докладлары буенча фикер алышуларда 2 мең кеше чыгып сөйләде.

Җыелышлар халык судларының эше белән хезмәт ияләренең бик нык кызыксынуларын күрсәтте. Алар докладчыларга күп санлы сораулар бирделәр, эштә булган җитешсезлекләрне бетерү өчен эшлекле тәкъдимнәр керттеләр.

Хезмәт ияләре халык судларына җидди таләпләр куялар. Алар Совет законнарын тайпылышсыз үткәрүне, растраталарга, социалистик милекне урлаучыларга каршы рәхимсез көрәш алып баруны, растратчикларны, каракларны, спекулянтларны, социалистик хокук тәртибен бозучы хулиганнарны һәм башка шундый җинаятчеләрне законнарның бөтен катылыгы белән җәзалауны халык судларыннан таләп итәләр.

Шуның белән бергә, гражданнар халык судларының гражданлык эшләрен [illegible] карауны, [illegible] буенча процессларны урыннарга барып үткәрүне, суд эшенең сыйфатын яхшыртуны, эшләрне закон белән билгеләнгән срокларда карауны, суд карарларын һәм приговорларын вакытында үтәүне тәэмин итүне, халык утырышчыларының юридик белемнәрен күтәрү буенча системалы рәвештә эш алып баруны таләп итәләр.

Халык судларының эшендә әле һаман да яшәп килә торган җитешсезлекләрне гражданнар үзләренең чыгышларында бик урынлы тәнкыйтьлиләр. 1940 нчы елда булып үткән җыелышлардагы чыгышлардан берничә мисаль китерик.

Куйбышев районы, Әҗмәр авылы гражданнарының җыелышында районның икенче участкы халык судьясе иптәш Вәкилевнең отчет доклады буенча чыгып сөйләгән гражданин Фәйзуллин,—халык суды тарафыннан суд утырышларына чакырып язылган повесткаларда гражданнарның кем сыйфатында, нинди эш буенча чакырылулары күрсәтелми, шуның нәтиҗәсе буларак, суд утырышларына чакырылучылар судта катнашуга тиешенчә хәзерләнә алмыйлар,—ди. Шулай ук ул, суд карарларының һәм приговорларының байтак кына эшләр буенча вакытында үтәлмәвен күрсәтеп, судның эшендә мондый практикага юл куймауны таләп итә.

Бауман районының (Казан) 72, 74, 75 һәм 76 нчы йорт идарәләре берләштергән йортларда торучыларның җыелышында 4 нче участкы халык судьясе иптәш Шәйдуллинның отчет доклады буенча чыгып сөйләгән гражданка Н.,—суд карары күптән инде закон көченә кергән булуга да карамастан, баласын тәрбияләү өчен элекке иреннән алимент акчасын, суд башкаручыларының эшлексезлеге аркасында ала алмавы турында күрсәтте. Зеленодольский шәһәрендә 2 нче участкы халык судьясе иптәш Касыймованың доклады буенча фикер алышуларда чыгып сөйләгән иптәш Молостов халык судьясенең масса белән элемтәсе җитәрлек булмавын, аеруча әһәмиятле эшләрнең урыннарга барып каралмавын, халык утырышчылары белән тиешенчә эш алып барылмавын әйтте.

Күп кенә җыелышларда гражданнар халык судьяләренең һәм халык судларының эше турында отчетларның хезмәт ияләре өчен әһәмияте зур булуын әйттеләр, бары тик совет суды гына—чын халык суды булуын, дәүләт һәм хезмәт ияләре интересларына хезмәт итүче, социалистик гадел хөкемне тормышка ашыручы суд булуын күрсәттеләр.

Югарыда күрсәтелгәнчә, халык судьяләренең күбесе халык алдында отчет бирүнең әһәмиятен дөрес аңлады һәм бу эшне регуляр рәвештә үткәрә башлады. 1939 нчы елда Тәкәнеш районы халык судьясе иптәш Сафиуллин 33, Куйбышев районының 1 нче участкы халык судьясе иптәш Арсентьев—20, Тымытык районы халык судьясе иптәш Булатов—20, Бондюг районының икенче участкы халык судьясе иптәш Архипов—12, Апас районының 1 нче участкы халык судьясе иптәш Гомәрев—16 отчет доклады ясадылар.

Ләкин, сайлаучылар алдында отчет бирүнең политик әһәмиятенә шушы көнгә кадәр бәя биреп җиткермәүче судьяләр дә бар әле. Мәсәлән, Молотов районының беренче участкы халык судьясе иптәш Сорокина, Кызыл Армия районы халык судьясе иптәш Ахунов, Киров районының икенче участкы халык судьясе иптәш Хатамуллин—сайлаучылар алдында отчет бирмиләр. Кайбер судьяләр бер-ике тапкыр отчет биреп, шуның белән үзләренең бурычын тәмамланган дип саныйлар. Мондыйлардан Казан шәһәренең Сталин районының 4 нче участкы халык судьясе Леванова, Молотов районының 4 нчы участкы халык судьясе Шәрипова, 6 нчы участкы халык судьясе Румянцев иптәшләрне күрсәтергә була.

Отчет җыелышларында хезмәт ияләре тарафыннан күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү буенча халык судьяләренең һәр вакытта да ашыгыч чаралар күрмәүләрен, сайлаучылар наказларының үтәлүе турында докладларны әледән-әле ясамауларын отчетларны үткәрүдәге җитешсезлекләрнең берсе итеп санарга кирәк.

Отчет җыелышларының начар оештырылуы, тиешле принципиаль югарылыкта үткәрелмәве турында да фактлар бар. Кайбер судьяләренең отчет докладларында тәнкыйть һәм үзеңне тәнкыйтьләү җитәрлек булмый. Бу хәл җыелышларның әһәмиятен киметә.

Халык судларының эше гомумән җитәрлек яктыртылмаган кебек үк, судьяләрнең халык алдында отчетлары да район газеталарында бөтенләй диярлек яктыртылмый. Моны аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк.

Халык судьяләренең халык алдында отчетлары—совет судының эш методларыннан берсе. Судьяләр халык алдында системалы рәвештә отчет бирергә тиешләр. Бу урында халык судьяләре Арсентьев һәм Вәкилев (Куйбышев районы), Новгородцева һәм Шәйдуллин (Казан шәһәре), Богомолов (Ширәмәт районы) һәм башка иптәшләрдән үрнәк алырга кирәк. Бу судьяләр 1940 нчы елның 1 нче кварталында гына да берничәшәр отчет ясадылар инде.

Шушы көнгә кадәр отчет бирүгә керешмәгән, яисә бер-ике отчет доклады ясау белән генә чикләнгән судьяләр артта калып баруны бетерергә тиешләр. Масса белән тыгыз элемтәдә булмый торып, эш масса контроле астына куелмый торып, халык судьяләре үзләренең эшен яхшырта алмыйлар һәм, димәк, эштәге җитешсезлекләрне дә бетерә алмыйлар. Моны халык судьяләре аңларга һәм онытмаска тиешләр.

Судьяләрнең отчет бирү эшенә җитәкчелекне тамырыннан яхшырту—ТАССР Юстиция Халык Комиссариатының бурычы әнә шул, Юстиция Халык Комиссариаты һәм Верховный Суд работниклары судьяләргә якыннан торып булышырга тиешләр. Халык судларының отчетларына багышланган җыелышлар тиешле принципиаль-политик югарылыкта үтсен өчен, халык судларының эшендәге җитешсезлекләр җыелышларда большевикларча тәнкыйть ителсен өчен партия, совет, комсомол һәм профсоюз оешмалары бу әһәмиятле политик чараны үткәрүгә җидди якын килергә һәм судьяләргә конкрет булышлык күрсәтергә тиешләр. Бу, суд органнары эшендәге җитешсезлекләрне тизрәк бетерергә, халык судларының эшен партиябез, хөкүмәтебез һәм халкыбыз тарафыннан куелган таләпләр югарылыгына, Сталин Конституциясе таләпләре югарылыгына күтәрергә ярдәм итәр.

Халык судларын Сталин Конституциясе нигезендә тиздән булачак сайлаулар судның эшен кискен рәвештә яхшыртуны, массалар белән элемтәне тагын да ныгытуны таләп итәләр. Орденлы республикабызның халык судьяләре моны намус белән үтәрләр.

Агафонов.

Чит илләрдә

АНГЛИЯНЕҢ ҺӘМ ФРАНЦИЯНЕҢ НОРВЕГИЯГӘ НОТАСЫ

ЛОНДОН, 8 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген Норвегия хөкүмәтенә Англия һәм Франция хөкүмәтләренең нотасы тапшырылган. Нотада аларның Германиягә үзенә кирәкле материалларны Норвегиядән алуына тоткарлык ясау һәм аларны алуга мөмкинлек бирмәү өчен үзләре тарафыннан кирәк дип табылган чараларны күрү хокукын үз кулларында калдырачаклары әйтелә. Аннары нотада, Норвегия суларының „контрабанда" йөкләре ташу өчен файдалану хокукын Англия һәм Франция хөкүмәтләренең кискен рәвештә инкар итүләре әйтелә. Һәр ике хөкүмәт, Норвегиянең территориаль суларындагы 3 районга миналар куелачагын һәм аларның пароходлар йөртү өчен куркынычлы булачагын кисәтәләр. Норвегия пароходлары һәм башка илләрнең пароходлары бу районнарга кермәсеннәр өчен шушы районнарга миналар куелганнан соң 48 сәгать буена Англиянең сугыш караблары саклап торачак.

Нотаның ахыргы өлешендә болай диелә:

„Һәр ике хөкүмәт Норвегиянең территориаль суларындагы түбәндә күрсәтелгән районнарның навигация өчен куркынычлы булуы турында хәбәр итә, чөнки анда миналар куелганлыкны белдерәләр:

Статланд—түбәндә күрсәтелгән урыннарны тоташтыра торган сызыклар белән Норвегия яры арасына урнашкан район: 1) төньяк киңлекнең 62 градус 11 минут 6 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 5 градус 6 минут 12 секунды, 2) төньяк киңлекнең 62 градус 9 минут 24 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 5 градус 0 минут 13 секунды, 3) төньяк киңлекнең 62 градус 12 минут 18 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 4 градус 49 минут 30 секунды, 4) төньяк киңлекнең 62 градус 19 минут 30 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 5 градус 3 минут 30 секунды, 5) төньяк киңлекнең 62 градус 12 минут 0 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 5 градус 3 минут 0 секунды.

Бод—түбәндә күрсәтелгән урыннарны тоташтыра торган сызыклар белән Норвегия яры арасына урнашкан район: 1) төньяк киңлекнең 67 градус 58 минут 27 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 7 градус 5 минут 30 секунды, 2) төньяк киңлекнең 67 градус 54 минут 0 секунды, 3) төньяк киңлекнең 63 градус 7 минут 12 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 7 градус 4 минут 30 секунды һәм 4) төньяк киңлекнең 62 градус 59 минут 24 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 7 градус 7 минут 15 секунды.

Вест-Фьорд—түбәндә күрсәтелгән урыннарны тоташтыра торган сызыклар белән Норвегия яры арасына урнашкан район: 1) төньяк киңлекнең 67 градус 24 минут 40 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 14 градус 34 минут 0 секунды, 2) төньяк киңлекнең 67 градус 27 минут 30 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 14 градус 7 минут 0 секунды, 3) төньяк киңлекнең 67 градус 28 минут 55 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 14 градус 6 минут 45 секунды, 4) төньяк киңлекнең 67 градус 33 минут 55 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 13 градус 51 минут 30 секунды, 5) төньяк киңлекнең 67 градус 37 минут 55 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 14 градус 2 минут 15 секунды һәм 6) төньяк киңлекнең 67 градус 26 минут 20 секунды һәм көнчыгыш озынлыкның 14 градус 38 минут 30 секунды".

Норвегия хөкүмәтенең декларациясе

ОСЛО, 8 апрель. (ТАСС). Норвегия телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Норвегия хөкүмәте, чит ил эшләре комиссиясе белән килешеп, Англиянең һәм Франциянең халыкара хокукны, Норвегиянең суверенитеты һәм нейтралитетын бозуларына каршы кискен протест белдереп, декларация игълан иткән.

Декларациядә бүген иртә белән Англия һәм Франция хөкүмәтләренең Норвегиянең территориаль суларында пароходларның иркле йөрешен туктату теләге белән бу сулардагы 3 районга миналар кую турында, шулай ук бу районнарны саклау өчен Англиянең сугыш корабларын җибәрү турында карарлар кабул иткәнлекләре әйтелә.

Декларациядә, Европадагы хәзерге сугыш башланганнан бирле Норвегиянең барлык билгеләнгән нейтралитет принципларын бик нык саклап килгәнлеге күрсәтелә. Норвегия хөкүмәте сугышучы илләрнең пароходларына Норвегиянең территориаль суларында йөрергә рөхсәт итүен нейтралитетның һәр кемгә билгеле булган шушы принципларына тулысынча туры китереп эшләгән иде. Хәзерге вакытта Англия һәм Франция хөкүмәтләре Норвегиянең территориаль суларында пароходлар йөртүне туктату чараларын күргәнлектән, Норвегия хөкүмәте үзен шушы елның 11 нче мартында Англия хөкүмәте кул куйган килешү турында искә төшереп утәргә мәҗбүр дип саный. Англия хөкүмәте Норвегия товарларының, хәтта контрабанда товарлар дип санала торган товарларның да Норвегиядән Германиягә сатыла алуына һәм озатыла алуына ризалык биргән иде. Норвегия хөкүмәте Англия һәм Франция хөкүмәтләренең көч ярдәме белән килеп катнашулары һәм Норвегиянең территориаль суларында пароходлар йөрешен туктатырга маташулары мөмкин икәнлекне күтәргә нигез бирерлек бер нинди начарлык та эшләмәде. Норвегия хөкүмәте сугышучы илләрнең Норвегиянең территориаль суларында миналар куюы белән һичбер хәлдә дә килешә алмый. Норвегия хөкүмәте Англиянең һәм Франциянең барлык куелган миналарны хәзер үк алуларын һәм Норвегиянең территориаль суларындагы үзләренең барлык сугыш корабларын кире алуларын таләп итә. Декларациядә Норвегиянең нейтралитетын саклау өчен кирәк дип санаган тиешле чараларны күрү хокукын Норвегия хөкүмәтенең үз кулында калдыруы күрсәтелә.

Норвегия телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген Норвегия хөкүмәте Англиянең һәм Франциянең Ослодагы илчеләренә Норвегиянең суверенитетын һәм нейтралитетын бозуга каршы протест белдереп заявление биргән. Заявлениенең эчтәлеге декларация эчтәлеге белән бер.

ГЕРМАНИЯНЕҢ СУГЫШ КАРАБЛАРЫНЫҢ ХӘРӘКӘТЕ

ОСЛО, 8 апрель. (ТАСС). Норвегия телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, барлыгы 90 нан 100 гә кадәр булган күп санда Германия сугыш карабларының төньякка, зур Бельта һәм Каттегат ягына таба киткәнлекләре расланa. Бу караблар, башлыча, кечрәк ярдәмче судноларда һәм коралланган траулерлардан торалар. Ләкин алар арасында зур күләмдәге сугыш караблары да күренгән.

НОРВЕГИЯНЕҢ СУВЕРЕНИТЕТЫН ҺӘМ НЕЙТРАЛИТЕТЫН АНГЛИЯНЕҢ БОЗУЫ ТУРЫНДА ШВЕЦИЯ МАТБУГАТЫ

СТОКҺОЛЬМ, 8 апрель. (ТАСС). Швециядә чыга торган „Нюа даглигт аллеханда" газетасы Англиянең Норвегия суларына миналар кую нәтиҗәсендә төньяк Норвегиянең көньяк Норвегиядән бөтенләй аерылганлыгын яза. Илнең бу ике өлеше арасында бары тик Швеция аркылы гына элемтә тотарга мөмкин. Шулай итеп Норвегиянең территориаль суларына Англиянең миналар куюы Швеция рудасын Германиягә җибәрүне дәвам иттерү мөмкинлеген бетерә. Газета: „Мина кырлары янына Британиянең көчле сакчылыгы куелган һәм шунлыктан Норвегия миналарны көч белән алып ташлый алмый" дип яза.

Аннары газета мина кырларының ничек урнашулары турында яза. Көнбатыш фиорд янындагы мина кыры нарвик бухтасына керү һәм аннан чыгу юлын бөтенләй яба. Кристиансунд һәм Стад янындагы кырлар фиордларда Норвегиянең нак диңгезгә кереп тора торган өлеше янындагы юлны ябалар.

„Нюа даглигт аллеханда" газетасының Лондондагы хәбәрчесе болай дип хәбәр итә:

„Союзникларның Германия пароходларының үтүенә тоткарлык ясау теләге белән Норвегиянең территориаль суларын блокадаларга карар бирүләренә Лондонда бик нык игтибар бирәләр һәм аны күп кенә даирәләрдә сугыш башланганнан бирле булган иң зур вакыйга дип карыйлар".

Дания газеталары үзләренең Берлиндәге хәбәрчеләреннән бик куркынычлы телеграммалар алдылар. Бер хәбәрче болай дип яза:

„Монда Германия бик тиз һәм һич тә көтелмәгәнчә хәрәкәт итәргә җыена дип уйлыйлар. Берлиндә, сугышның яңа фазасы башланганлыкны әйтәләр".

Аннары „Нюа даглигт аллеханда" газетасы болай дип яза:

„Бүген иртә белән көнбатыш державалар сүздән эшкә күчтеләр. Англиянең һәм Франциянең Норвегия суларына миналар куюлары Норвегиянең нейтралитетын иң тупас рәвештә бозу. Бу, хәзер инде төньяк илләрнең бөек державалар арасындагы сугышка тартылулары моннан элек булганга караганда да ихтималрак дигән сүз".

Газета, Германия җидди җавап чаралары күрер дип курка.

„Афтонбладет" газетасы үзенең баш мәкаләсендә Лондонның һәм Парижның позициясен бик нык тәнкыйть итә. Газета болай дип яза:

„Норвегиянең территориаль суларына Англиянең миналар куюы ачык бер теләк белән, ягъни транспортларны Англиянең сугыш караблары очрата алсын өчен аларны территориаль сулардан ачык диңгезгә чыгарга мәҗбүр итү теләге белән эшләнгән. Бу—саф сугыш акты. Ул Норвегия территориясендә эшләнде һәм ул Норвегиянең суверенитетына каршы килә."

Швециядә чыга торган кичке „Нюа Даглигт аллеханда" газетасының Копенһагеннан алып хәбәр итүенә караганда, бүген иртә белән төньякка таба Каттегатка киткән Германия сугыш корабларының саны 100 чамасына җитә. Алар арасында коралланган тральщиклар, сакчылык караблары һәм зур күләмдәге сугыш караблары бар. Даниядәге диңгез даирәләре, Германиянең диңгез экспедициясенең теләге—Норвегия белән һәм Швециянең көнбатыш яры белән элемтә юлын ачык калдырып, Дания ярларына кадәр Норвегиянең көньяк ярындагы суларга миналар кую, дип уйлыйлар.

Шул ук газетаның Ослодагы хәбәрчесе Германиянең зур күләмдәге диңгез көчләренең Норвегия һәм Дания ярлары арасында хәрәкәт итүләре турындагы хәбәрне раслый. Норвегия ярларыннан Германиянең 50 ләп сугыш корабларыннан торган эскадрасын күргәннәр.

Германия армиясе верховный командованиесенең махсус белдерүе

БЕРЛИН, 9 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәге махсус белдерүне игълан иткән: „9 нчы апрельдә иртә белән Германиянең моторлаштырылган частьләре һәм броне көчләре Фленсбург һәм Тондерн районында Германия—Дания чиге аркылы үтеп чыктылар, Апенраде һәм Эсбьерг аркылы төньякка таба хәрәкәт итүдә дәвам итәләр. Таң алдыннан Германия гаскәрләре кечкенә Бельт проливына керделәр һәм Бельт аркылы салынган күперне алдылар. Германиянең хәрби диңгез көчләре Зур Бельт проливына барып керделәр, Корсергә һәм Нибургка гаскәр төшерделәр. Варнов елгасы тамагында Германия частьләре Гледжерга төшерелделәр һәм аннан төньякка таба хәрәкәт итә башладылар. Бер үк вакытта Зееланд атауының көньяк өлешендә Вордингборг күпере алынды. Таң алдыннан Германия гаскәрләре Копенһагенга керделәр. Крепость һәм радио станция Германия гаскәрләре тарафыннан алынды. 8 сәгаттән бирле бөтен шәһәр немецләр кулында"

ГЕРМАНИЯ ГАСКӘРЛӘРЕ ТАРАФЫННАН БЕРГЕННЫҢ ҺӘМ ТРОНГЕЙМНЫҢ АЛЫНУЛАРЫ ТУРЫНДА

НЬЮ-ЙОРК, 9 апрель. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының, Америка радио компаниясе „Колумбия Бродкэстинг систем" ның Лондон бүлеге хәбәрләре буенча, Бергенның һәм Тронгеймның Германия гаскәрләре тарафыннан алынуларын хәбәр итә.

ГЕРМАНИЯ АРМИЯСЕ ВЕРХОВНЫЙ КОМАНДОВАНИЕСЕНЕҢ СВОДКАСЫ

БЕРЛИН, 9 апрель. (ТАСС). Германия информацион бюросы Германия армиясе верховный командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „Ютландиядә Германия гаскәрләренең төньякка хәрәкәте һәм атаулардагы хәрәкәт тиз һәм уңышлы рәвештә тормышка ашырыла. Дания хөкүмәте бернинди каршылык күрсәтмәү турында үзенең гаскәрләренә приказ бирде. Германия һәм Дания штаблары бүген иртән үзара элемтә урнаштырдылар. Норвегиянең барлык урыннарындагы иң мөһим опорный пунктларны Германия гаскәрләренең оккупацияләве бик тиз темп белән бара. Армиянең барлык өч төре дә үзара бәйләнеш тоткан хәлдә операция алып баралар. Норвегия гаскәрләренең кечкенә генә каршылык күрсәтүләре туктатылды. Ютландия һәм көньяк Норвегиядәге аэродромнарга Германиянең һава көчләре төште.

САНИТАРИЯ КУЛЬТУРАСЫ ЙОРТЫНДА

Казанда Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариатының Санитария Культурасы йорты 1932 нче елдан бирле эшләп килә.

Хезмәт ияләре арасында санитария белемен таратуда һәм гигиена кагыйдәләрен урнаштыруда Санитария Культурасы йорты зур әһәмиятле урынны тота. Аның янында музей бар. Музейдә анатомия, хәрби-санитария, аналарны һәм балаларны саклау, профессиональ авырулар, венера авырулары, йогышлы авырулар, малярия һәм туберкулез бүлекләре оештырылган. Алардагы экспонатлар авырулардан саклану һәм дәвалану юлларын күрсәтәләр.

Санитария Культурасы йортында лекция залы һәм тавышлы кино бар. Клубларда, предприятиеләрдә, больницаларда лекцияләр үткәрелгәндә күчмә кино аркылы да сеанслар бирелә. Аларда сәламәтлек саклауга карата эшләнгән фильмнар күрсәтелә. Татарстан районнарында да күчмә кинолар эшләп килә. Күчмә кинолар шушы елның беренче кварталында санитариянең төрле тармаклары буенча лекцияләр укыганда 300 дән артык колхозга хезмәт күрсәттеләр.

Трахома авыртына каршы көрәшү өчен Тельман, Аксубай һәм Октябрь районнарында санитария бригадалар төзелә.

Хезмәт ияләре санитария белеме белән бик нык кызыксыналар. Предприятиеләр һәм учреждениеләр Санитария Культурасы йортына экскурсияләр оештыралар. Предприятиеләрдә, больницаларда, клубларда әледән-әле лекцияләр үткәрелә. Казанда лекцияләрне РСФСР Верховный Советы депутаты профессор Агафонов, профессор Маненков, профессор Мурзин, врачлардан Шмулевич, Левин, Губанова, Гобәйдуллина иптәшләр һәм башкалар үткәрәләр. Узган елны Казанда 1.235 лекция үткәрелеп, аларны 74 меңнән артык кеше тыңлады. 33 лекцияне Врачларның белемен күтәрү институты профессорлары һәм доцентлары үткәрделәр. Татарстан районнарында үткәрелгән 804 лекцияне 38 меңнән артык кеше тыңлады.

Узган ел Санитария Культурасы йорты тарафыннан Казанда һәм районнарда 1.300 гә якын кино-сеанс бирелеп, аларны 75 меңнән артык кеше карады.

Быелгы план буенча Казанда һәм районнарда 2.000 лекция үткәрергә билгеләнде. Грипп авыруына һәм балаларда була торган эч китү авыруларына каршы көрәш буенча апрель, май айларында Казанда һәм районнарда лекцияләр, шулай ук радио аркылы беседалар үткәреләчәк.

Санитария Культурасы йорты РОКК оешмалары белән якыннан элемтә тотып эшли. „ГСО" значкистлары хәзерләүдә аларга зур булышлык күрсәтә.

Г. Латыйпов.

Комсомолның 15 еллыгы исемендәге стипендия

Казан Авыл Хуҗалыгы институтының агрономия факультеты студенты иптәш И. Ф. Новичковка 1940 нчы елның февраленнән комсомолның 15 еллыгы исемендәге стипендия билгеләнде. Иптәш Новичков 1939—40 нчы уку елының кышкы сессиясендә бөтен фәннәр буенча сынауларны отлично билгесенә тапшырды. Ул институтта җәмәгать эшләренә дә актив катнаша. Иптәш Новичков 3 елдан бирле комсомол комитеты секретаре булып эшли. СССР Верховный Советына сайлаулар кампаниясендә ул институтта сайлаулар эше буенча оештыру эшләрен алып барды. Җирле Советларга сайлауларда доверенный хезмәтен үтәде.



Казан шәһәр телефон станциясенең иң яхшы телефонисткасы Е. Т. Кабанова. Ул 150 абонент урынына 225 абонентка хезмәт күрсәтә.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ПОЧЕТ КНӘГӘСЕНӘ КЕРТЕЛДЕЛӘР

1939 нчы елның декабрендә РСФСР Мәгариф Халык Комиссариаты тарафыннан почет кнәгәсе расланган иде. Почет кнәгәсенә культура-агарту, агрономия, хәрби-оборона эшләрен һәм дингә каршы пропаганданы, укый-яза белмәүчелекне бетерү, аз белемлеләрне укыту эшен һәм бездә докладларны үрнәк булырлык итеп оештыручы политик-агарту работниклары кертеләләр.

Халык арасында культура-масса һәм политик агарту эшләрен яхшы оештыручылар өчен Татарстан районнарында эшләүче политик-агарту работникларыннан 11 кеше РСФСР Мәгариф Халык Комиссариаты коллегиясе карары белән Почет кнәгәсенә кертелделәр. Алар арасында Зиннәтуллина Ф. (Биектау районы Яңа Ширмә уку өе мөдире), Ануръев Николай Прокофьевич (Аксубай районы, Яңа Тимошкино уку өе мөдире), Фәйзуллина Миңсылу (Саба районы политик-агарту эшләре инспекторы) һәм башка иптәшләр бар.

ФУКО МАЯТНИГЫ

Хезмәт ияләре Татарстанның дингә каршы музеендә оештырылган Фуко маятнигын зур кызыксыну белән карыйлар. 15 көн эчендә маятникны 5.700 кеше карады.

Предприятиеләр һәм учреждениеләр анда экскурсия оештыралар. Шушы көннәрдә Фуко маятнигына Казан пристаненең эшчеләре һәм хезмәткәрләренең экскурсиясе булды. Арча һәм Биектау районнарыннан да экскурсияләр оештырылды.

Фуко маятнигын карарга килүчеләр өчен Казан Дәүләт университетының астрономия бүлеге студентларыннан төзелгән лекторлар группасы лекцияләр укый. Лекторлар дөньяның яралуын һәм үсүен, җирнең үз күчәре әйләнәсендә хәрәкәтен аңлаталар. Экскурсантлар дингә каршы көрәшүдә, руханиларның ялганнарын ачып салуда Фуко маятнигының зур роль уйнаганлыгын әйтеп, үзләренең фикерләрен язып калдыралар.

Хәзерге көндә дингә каршы музейнең башка бүлекләрен оештыру эшләре бара.

Яз

Г. Поляков фото-этюды.

УҖЫМНАРНЫҢ ТОРЫШЫ ЯХШЫ

Шөгер районында уҗымнар кар астыннан яхшы хәлдә чыктылар. Колхозлардагы лабораторияләрнең тикшерүләре күрсәткәнчә, һәлак булган уҗымнар бик аз. „Яш көч", „Алтай", „1 Мая" һәм Куйбышев исемендәге колхозларда уҗымнарның бер проценты да һәлак булмаган. (ТатТАСС).

Җәйге сезонда балалар ясләре һәм мәйданчыклары

1940 нчы елда СССР да сезонлы ясләләргә, балалар мәйданчыкларына 5 миллионнан артык бала тартыла.

ССР Союзы Җир Эшләре, Сәламәтлек Саклау һәм РСФСР Мәгариф Халык Комиссариатлары барлык җир органнары работникларына, укытучыларга, культура фронтының башка работникларына, шулай ук авыллардагы барлык медицина работникларына мөрәҗәгать итеп, колхозлардагы балалар учреждениеләрен үрнәк булырлык итеп оештыруда ярдәм итәргә чакырдылар. Апрель аенда балалар учреждениеләрен ачуга хәзерлекне тикшерү буенча рейдлар үткәреләчәк.

ЕЛГАЛАРДА

Волга суы 9 нчы апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Горький янында 28 сантиметр, Кама Тамагы янында 46 сантиметр, Тәтеш янында 62 сантиметр артты. Казаннан түбән боз кузгалу сәбәпле Югары Ослан янында 7 сантиметр су кимеде. Бөтен арткан су 4 метр 8 сантиметрга калды, Аргы Усия яны боздан арчылды. Вязовые һәм Тәтеш янында да боз кузгалды.

Кама суы Молотов шәһәре янында 33 сантиметр, Красный Бор янында 47 сантиметр, Чистай янында 35 сантиметр, Лаеш янында 48 сантиметр артты. Чистай һәм Лаеш янында боз кузгалды.

Агыйдел суы Бирски янында 35 сантиметр артты. Уфа яны боздан арчылды.

Оканың югары ягында боз агып бетте. Кашира янында боз ага. Рязань һәм Горький янында Ока бозы кузгалды.

Сура елгасында боз ага. Алатырь янында 30 сантиметр су артты. Иж елгасында көчле рәвештә боз ага.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ
Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитетыны
МӘҖБҮРИ КАРАРЫ № 4
1940 нчы ел, 27 нче март.

Дуңгызларның рожа белән авыруларын булдырмау теләге белән, Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты карар бирә:

1. Шәһәр җир бүлеген,—шушы ел апрель аенда, дәүләт һәм кооператив оешмаларының, шулай ук частьный кешеләрнең дуңгызларына, рожа авыруына каршы, профилактик чаралар (вакцинация) үткәрергә мәҗбүр итәргә.

2. Рожа авыруына карата профилактик чаралар: дәүләт һәм кооператив хуҗалыкларның дуңгызларына—шул хуҗалыкларга беркетелгән ветперсонал тарафыннан, шул хуҗалык хисабына, ә частьный кешеләрнең дуңгызларына—шәһәрдәге ветеринария-дәвалау учреждениеләрендә, түләүсез үткәрелә.

3. Дуңгызлары булган барлык гражданнар үзләренең дуңгызларын шушы ел 15 нче апрельгә кадәр түбәндәге пунктларда теркәтергә тиешләр:

а) Сталин районында—Шәһәр Ветеринария поликлиникасында (Париж Коммунасы мәйданында, 1-3).

б) Ленин районында—Ленин районының ветеринария-дәвалау йортында (Селекат заводы янындагы тукталыш).

в) Бауман һәм Молотов районнарында—Ветеринария Инфекция клиникасында (Калуга, 8 нче площадка).

г) Киров районында—Киров районы Ветеринария поликлиникасында (Краснококшай урамы, 36).

4. Бу мәҗбүри карарны бозуда гаепләнүчеләр административ җаваплылыкка: 100 сумга кадәр штрафка яисә 30 көнгә кадәр мәҗбүри хезмәткә тартылалар.

5. Бу карарның үтәлешен күзәтү йорт идарәләренә һәм Дәүләт Ветеринария надзорына йөкләтелә.

6. Мәҗбүри карар, игълан ителгән көннән алып, 15 көннән соң үз көченә керә һәм Казан шәһәре территориясендә 1940 нчы ел буена гамәлдә булып кала.

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ.

АВТОХУҖАЛЫКЛАР ИГТИБАРЫНА!

Йөк автомашиналарын, бортларында трафарет язуы булмаган һәм номерлы знаклары пычранган яисә янчелгән хәлдә йөртү хәлләре ешаю уңае белән,

Татарстан АССР НКВД Эшче-Крестьян Милициясе Идарәсе автохуҗалыкларның барлык җитәкчеләренә КИСӘТҮ БЕЛДЕРӘ:

Йөк автомашиналары, бортларында трафарет язуы булмаган һәм номерлы знаклары пычранган яисә янчелгән хәлдә, линиягә чыксалар, бу җитешсезлекләре буенча гаепле кешеләр Эшче-Крестьян Милициясе органнары тарафыннан штрафка тартылачак.

Эшче-Крестьян Милициясе Идарәсе.
592—1

ТАТАРСТАН АССР ДАГЫ БАРЛЫК
АВТОМАШИНА ҺӘМ МОТОЦИКЛ ХУҖАЛАРЫ ИГТИБАРЫНА
Татарстан АССР НКВД Эшче-Крестьян Милициясе Идарәсенең
ДӘҮЛӘТ АВТОИНСПЕКЦИЯСЕ
1940 нчы ел 20 нче апрельдән авто-мото транспортка
ЯРТЫ ЕЛЛЫК ТЕХНИК ОСМОТР ҮТКӘРӘ
Тиешле инструктаж алу өчен, автомашина һәм мотоцикл хуҗаларына шушы ел 20 нче апрельгә кадәр урындагы милиция бүлекләренә килергә тәкъдим ителә.
Дәүләт автоинспекциясе.
593—2—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Бүген, 10 нчы апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Иртәгә, 11 нче апрельдә
КАЧКЫН
Талоннар белән кертелми.
Кич 8 сәгатьтә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
12 нче апрельдә көндез һәм кич
ШӘМСЕКАМӘР
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 8 сәгатьтә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

Казан Шәһәр Ветеринария бүлеге паспорт пунктының урланган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга.
596—1

Казан Дәүләт Мединституты Акушерка-Гинекология клиникасының овал формадагы урланган печатен гамәлдән чыккан дип санарга.
574—1

КИРӘК:
Казан Эпидемиология һәм Микробиология институтына даими эшкә КАРТОТЕКАЧЫ, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАР һәм термос, шулай ук автоклав эшләрен белүче СЛЕСАРЬ. 575—3—3

АВТОКУЗОВНЫЙ ЗАВОДКА (Эшчеләр бистәсе, Набережный урам, 11) БАШ МЕХАНИК, ФИНАНС БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР һәм 5—6 нчы РАЗРЯД КАЛАЙЧЫЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Заводның кадрлар бүлегенә килергә. 584—3—3

Ленин исемендәге Сукно фабрикасына (Казан, Киров районы, Гладилов урамы, 59) даими эшкә НОРМАЛАУЧЫ, СЕКРЕТАРЬ-МАШИНИСТКА, ПРОИЗВОДСТВО БУХГАЛТЕРЫ һәм МАТЕРИАЛЬ БҮЛЕК ӨЧЕН КАРТОТЕКАЧЫ. 585—2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 10 нчы һәм иртәгә 11 нче апрельдә
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
12 нче апрельдә көндез
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО" 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм АРИНКА
„УНИОН" 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" 6, 8, 10 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ЧАТКЫ" 6, 8, 9-30 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ПИОНЕР" 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	КАБАРДА АТЛЫСЫ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник" 6, 8 һәм 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„РОТ-ФРОНТ" 6, 8, 10 да.	КАТЕРИНА
КУЛЬТУРА САРАЕ	Кече залда, 5, 7 һәм 9 да ГРОЗА; Зур залда, кич 10 да ҖИР ПЛЕНДӘ